ФГОС

Р. З. Хайдарова, Г. М. Ахметзянова

# ТАТАР ТЕЛЕ

## 5 класс



Татармультфильм

ИЗДАТЕЛЬСТВО
«Татармультфильм»

# Россия Федерациясе гимны
# Гимн Российской Федерации

Слова С. Михалкова
Музыка А. Александрова

Россия — священная наша держава,
Россия — любимая наша страна.
Могучая воля, великая слава —
Твоё достоянье на все времена!

Славься, Отечество наше свободное,
Братских народов союз вековой,
Предками данная мудрость народная!
Славься, страна! Мы гордимся тобой!

От южных морей до полярного края
Раскинулись наши леса и поля.
Одна ты на свете! Одна ты такая —
Хранимая Богом родная земля!

Славься, Отечество наше свободное,
Братских народов союз вековой,
Предками данная мудрость народная!
Славься, страна! Мы гордимся тобой!

Широкий простор для мечты и для жизни
Грядущие нам открывают года.
Нам силу даёт наша верность Отчизне.
Так было, так есть и так будет всегда!

Славься, Отечество наше свободное,
Братских народов союз вековой,
Предками данная мудрость народная!
Славься, страна! Мы гордимся тобой!



## Татарстан Республикасы гимны
## Гимн Республики Татарстан

Р. Байтимеров сүзләре
Р. Яхин музыкасы

Мәңге яшә, газиз Ватаныбыз,
Халкым тели изге теләкләр!
Гомерлеккә якын туган булып
Яши бездә төрле милләтләр.
Күп гасырлар кичкән чал тарихлы
Данлы илем, үзең бер дастан!
Синдә генә безнең язмышыбыз,
Республикам минем, Татарстан!

Цвети, священная земля моя,
Да будет мирным твой небосвод!
Единый дом у нас, одна семья,
Живёт в согласии наш народ.
Богатый мудростью седых веков,
Надеждой, верою ты нам стал,
И пусть хранит тебя моя любовь,
Моя республика, мой Татарстан!

Тыңла
һәм
өйрән

Р. З. Хәйдәрова, Г. М. Әхмәтҗанова

# ТАТАР ТЕЛЕ

# 5

## БИШЕНЧЕ СЫЙНЫФ

ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ
ОЕШМАЛАРЫ ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕК
(ТАТАР ТЕЛЕН БАШЛАП ӨЙРӘНҮЧЕ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН)

ДӘРЕСЛЕК Е. И. ПАССОВНЫҢ
КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯ КОНЦЕПЦИЯСЕНӘ
НИГЕЗЛӘНӘ

КАЗАН
«ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ» НӘШРИЯТЫ
2025

Р. З. Хайдарова, Г. М. Ахметзянова

# ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК

# 5

## ПЯТЫЙ КЛАСС

УЧЕБНИК ДЛЯ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЙ
ОСНОВНОГО ОБЩЕГО ОБРАЗОВАНИЯ
(ДЛЯ ОБУЧАЮЩИХСЯ, НЕ ВЛАДЕЮЩИХ
ТАТАРСКИМ ЯЗЫКОМ)

НА ОСНОВЕ КОНЦЕПЦИИ КОММУНИКАТИВНОЙ
ТЕХНОЛОГИИ Е. И. ПАССОВА

КАЗАНЬ
ИЗДАТЕЛЬСТВО «ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ»
2025

УДК 811.512.145(075)
ББК 81.632.3я72
Х18

## Условные обозначения

Начало урока

Запомни!

Вспомни!

Произноси правильно!

Работа в парах

Творческая работа

Инсценирование

Ситуативные упражнения

Вместе посмеёмся!

**Хайдарова, Р. З. и др.**

Х18 Государственный (татарский) язык Республики Татарстан: Татар теле. 5 класс: учебник для образовательных организаций основного общего образования (для обучающихся, не владеющих татарским языком) / Р. З. Хайдарова, Г. М. Ахметзянова. — Казань : Татармультфильм, 2025. — 144 с.: ил.

ISBN 978-5-906508-55-3

**ISBN 978-5-906508-55-3**

**УДК 811.512.145(075)**
**ББК 81.632.3я72**

© Татармультфильм, 2025
© Художественное оформление.
Татармультфильм, 2025
Все права защищены

# БЕЗ МӘКТӘПТӘ



## 1–2 нче дәресләр

**1.** Бер-берегезгә (друг другу) яхшы сүзләр әйтегез, яхшы теләкләр (пожелания) теләгез. Җөмләләрне таблицага урнаштырыгыз.

| Исәнләшү | Саубуллашу | Яхшы теләкләр |
|---|---|---|
| ... | ... | ... |

Исәнме, Марат! Котлыйм! Исәнмесез, Зифа апа! Сәлам, Гүзәл! Уңышлар телим! Хушыгыз, Илдар абый! Хуш, Мансур! Яхшы кәеф телим! Саумысыз, Азат абый! Саумы, Гүзәл! Сәламәтлек телим! Сау булыгыз, Мәликә апа! Сау бул, Иркә!

**2.** Сүзләрне дөрес укыгыз, тәрҗемәләрен исегезгә төшерегез. Алар сезгә котлау (поздравление) язарга ярдәм итәр.

[бә̆лә́м көне́], [кө̆тлө́йм], [уңы̆шла́р], [сәләмәтлә́к], [бә̆лә́н], [укы̆тучы́], [хөрмәтлә́].

**3. Исегезгә төшерегез!**

**кем?** (кто?) — син, сез
**кемне?** (кого?) — сине, сезне
**кемгә?** (кому?) — сиңа, сезгә
Сине (сезне) Белем көне белән котлыйм!
Сиңа (сезгә) уңышлар телим!



**4.** Ә сез укытучыларны Белем көне белән котладыгызмы? Бирелгән сүзләрдән җөмләләр төзегез, котлау языгыз.

Хөрмәтле, укытучым, котлыйм, Сезне, уңышлар, телим, Белем көне, белән, Сезгә, сәламәтлек.

**5.** Әйтик, сез бәйрәмдә, ди. Җөмләләрне кулланып, бер-берегезгә комплиментлар әйтегез.



Синең күлмәгең (костюмың) бик матур!
Синең чәчләрең бик матур!
Күлмәгең бик матур!
Нинди матур бантик!
Син бик матур!
Син бүген бик матур!

**6.** Рәсемнәр урынына сүзләр куеп укыгыз. Җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз.

Бүген 

бәйрәме. Мәктәптә күңелле. Мин укытучыга  бүләк итәм. Оля 

бүләк итә. Укытучылар бик шат. Без дә шат.

**7.** Текстны сөйләргә өйрәнегез.

## 3 нче дәрес

**1. Исегезгә төшерегез!**

**Исемнәрнең тартым белән төрләнеше**
Имена существительные с аффиксами принадлежности

| Зат | Тартыкка беткән исемнәр | Сузыкка беткән исемнәр |
|---|---|---|
| I зат | карандаш-ым<br>дәфтәр-ем | хата-м<br>чия-м |
| II зат | карандаш-ың<br>дәфтәр-ең | хата-ң<br>чия-ң |
| III зат | хата-сы<br>чия-се | хата-сы<br>чия-се |

**2. Исегездә калдырыгыз!**

В именах существительных, оканчивающихся на **-к, -п,** при добавлении аффиксов принадлежности **-ым/-ем, -ың/-ең, -ы/-е** буквы **-к** и **-п** чередуются с **г** и **б**:

кенд**ә**ле**к** — кенд**ә**ле**г**ем    к**ү**лм**ә**к — к**ү**лм**ә**гем
урынды**к** — урынды**г**ым    ту**п** — ту**б**ым

**3.** Уку-язу әсбапларының исемнәрен искә төшерегез. Сезнең нинди уку-язу әсбапларыгыз бар?




**4.** Нокталар урынына **сумка**, **дәфтәр**, **китап** сүзләрен куеп языгыз.

Минем ... .
Синең ... .
Аның ... .

**5.** Исемнәрне тартым белән төрләндерегез.

Китап, туп, күндәлек.

**6.** Спросите у соседа по парте:

а) есть ли у него:
— тетрадь (в клетку, в линейку);
— цветные карандаши;

б) где находится его сумка.

# 4 нче дәрес

**1.** **Исегезгә төшерегез!**

**кая?** — куда?
**кайда?** — где?
**кайдан?** — откуда?

**2.** Рәсемнәргә карагыз һәм әйтегез: Дима кая бара? Дима кайда? Дима кайдан кайта?









**3.** Спросите у Димы:

— идёт ли он в школу;
— учится ли он в школе;
— возвращается ли он из школы.

**4.** Схема буенча җөмләләр төзегез.

дәфтәрне
Мин — китапны — **кайдан?**  алам, **кая?**  салам.
ручканы

**5.** Диалогка төшеп калган репликаларны куеп языгыз. Дустыгыз белән сөйләшегез.



— ... ?

— Әйе, мин дәфтәрләрне өстәлдән алдым.

— ... ?

— 5 дәфтәр алдым.

— ... .

**6.** Җөмләләрне киңәйтеп языгыз. Һәр җөмләгә сорау куегыз.

Ү р н ә к: Дәфтәр бар. Сумкада дәфтәр бар. Сумкада шакмаклы дәфтәр бар. Сумкада өч шакмаклы дәфтәр бар.

Җ ө м л ә л ә р: Ручка бар. Китап бар.

**7.** Какие вопросы вы зададите, чтобы получить такие ответы? По содержанию получившегося диалога поговорите друг с другом.

— ... ?

— Мин бишенче сыйныфта укыйм.

— ... ?

— Әйе, минем китабым бар.

— ... ?

— Мин мәктәпкә барам.

**8.** Попросите у друга:





Как спросите, есть ли у друга:





Спросите, есть ли в его сумке:






# 5–6 нчы дәресләр

**1.** Сүзләрне дөрес укырга өйрәнегез, тәрҗемә итегез.

[ғәҗә́п], [йаºңа́], [қŏтло́й], [күңӗлсә́с], [кулы̆нда́], [күңӗ̄лә́], [кә̆шӗләргә́].

**2.** Исегезгә төшерегез: бу сүзләр ничек языла? Нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз һәм дәфтәрегезгә языгыз.

Г...җәп, б...ген, табиг...ть, кү...елсез, я...гыр, к...яшлы, ук...чы, б...ел, ук...тучы, сыйн...ф, х...рмәтле.

**3.** Сүзләрнең антоним парларын табыгыз.

| | |
|---|---|
| көн — ... | бүген — ... |
| матур — ... | җылы — ... |
| узган ел — ... | яңа — ... |

**4.** Бирелгән сүзтезмәләр белән җөмләләр төзегез. Ул җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз.

Узган ел, күңелле музыка, сыйныф җитәкчесе, чәчәк бәйләме, хөрмәтле кешеләр.

**5.** Текстны укыгыз. Анда нинди көн турында сүз бара?

Бүген 1 нче сентябрь. Көн гаҗәп матур. Табигать безне яңа уку елы белән котлый. Узган ел бу көнне күңелсез булды, яңгыр яуды. Ә быел җылы, кояшлы.



Бүген мәктәптә Белем бәйрәме. Мәктәптә күңелле музыка уйный. Без Россия һәм Татарстанның Дәүләт гимннарын тыңладык. Укучылар да, укытучылар да матур киенгәннәр. Укучыларның кулында чәчәкләр. Әлбәттә, алар иң хөрмәтле кешеләргә — укытучыларга!

**6.** Рәсемнәргә туры килгән җөмләләрне тексттан табып укыгыз.





**7.** Сүзләрнең тәрҗемәсен табыгыз.

| | |
|---|---|
| бәйрәм | природа |
| гаҗәп | уважаемый |
| табигать | праздник |
| хөрмәтле | удивительно (изумительно) |

**8.** Җөмләләрне текст эчтәлеге буенча (по содержанию текста) урнаштырыгыз.

1. Укучылар да, укытучылар да матур киенгәннәр. 2. Узган ел бу көнне күңелсез булды, яңгыр яуды. 3. Мәктәптә күңелле музыка уйный. 4. Көн гаҗәп матур. 5. Ә быел җылы, кояшлы. 6. Табигать безне яңа уку елы белән котлый.

**9.** Сез бу раслаулар белән (с утверждениями) килешәсезме?

— Беренче сентябрьдә көн күңелле булды.

— Узган елны беренче сентябрьдә яңгыр яуды.

— Укучылар мәктәпкә чәчәкләр алып килгәннәр.

— Укучылар чәчәкләрне укытучыларга бирделәр.

**10.** Җөмләләрне язып бетерегез. Җөмләләргә сораулар куеп, үзара сөйләшегез.

Бүген көн … . Узган ел беренче сентябрь … . Ата-аналар да матур … . Укучылар укытучыларны … . Без чәчәкләрне … . Бәйрәмдә Россиянең һәм Татарстанның … яңгырый.

**11.** Спросите у друга о том:

— какая сегодня погода;
— как прошёл в школе праздник;
— кому он подарил цветы;
— кого он поздравил с праздником.

**12.** Текстны иң матур сөйләүчегә конкурс! Сөйләүчегә бәя бирергә (оценить) онытмагыз.




**13.** Сезнең мәктәптә бәйрәм ничек узды? Кечкенә хикәя төзеп, дәфтәрегезгә языгыз. Үзегез язган хикәяне сөйләргә өйрәнегез.

**14.** Бирелгән диалог буенча сөйләшегез.

— Россиянең Дәүләт гимны бармы?

— Әйе, бар. Авторлары: Сергей Михалков һәм Александр Александров.

— Татарстанның Дәүләт гимны бармы?

— Әлбәттә, бар.

— Гимн музыкасының авторы кем?

— Рөстәм Яхин.

— Сүзләрен кем язган?

— Рамазан Байтимеров.

— Дәүләт гимны кайларда яңгырый (звучит)?

— Бәйрәмнәрдә, зур концертларда, спорт ярышларында (на спортивных соревнованиях).

## 7–8 нче дәресләр

**1.** Рәсемгә карагыз: ике малай нәрсә турында сөйләшә? Диалог төзегез.



**2.** Сүзләрне дөрес укырга өйрәнегез, тәрҗемә итегез.

[йаºзма́ эш], [уқы̆тучы̆́], [хаºтасы̆́с].

**3.** Җөмләләрне укыгыз, тартымлы исемнәрне (имена существительные с аффиксами принадлежности) табыгыз. Тартым кушымчаларын күрсәтегез. Җөмләләрне кулланып, диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

1. Минем дәреслегем яңа, ә синең дәреслегең нинди? 2. Язма эшем дөрес һәм чиста, ә синең хатаң бармы? 3. Бүген дәфтәрем өйдә калган. 4. Аның язма эше хатасыз, ә синең хатаң бармы? 5. Минем дәфтәрем партада, ә синең дәфтәрең кайда?

**4.** Составьте словосочетания из данных слов.

| | | |
|---|---|---|
| мисал | | |
| мәсьәлә | | чиштем |
| контроль эш | ? | бирдем |
| җавап | | яздым |
| сорау | | әйттем |
| күнегү | | эшләдем |
| диктант | | |

**5. Исегезгә төшерегез!**

Вы уже знаете, что к основе имени существительного сначала присоединяется аффикс числа, затем аффикс принадлежности и падежный аффикс:

| Основа | + аффикс мн. числа | + аффикс принадлежности | + аффикс падежа |
|---|---|---|---|
| күз | **-ләр** | **-ем** | **-нең** |
| курчак | **-лар** | **-ым** | **-ны** |

**6. Исегездә калдырыгыз!**

минем дәфтәр**ем-дә** — в моей тетради
диктант**ым-да** — в моём диктанте
синең дәфтәр**ең-дә** — в твоей тетради
диктант**ың-да** — в твоём диктанте
аның дәфтәр**е-ндә** — в его (её) тетради
диктант**ы-нда** — в его (её) диктанте

**7.** Үрнәк буенча дәвам итегез.

Үрнәк: минем китабым — китабымда, синең китабыңда
минем мисалым — …
минем контроль эшем — …
минем мәктәбем — …

**8.** Диалогка төшеп калган репликаларны өстәгез, сөйләшергә өйрәнегез.

1. — … ?
— Әйе, контроль эш эшләдем.
— Нинди фәннән?
— … .
— … ?
— Мисалымда ике хата бар иде.
— … ?
— Ә мәсьәләне дөрес чиштем.

2. — … ?
— Юк, минем контроль эштә хата юк.
— … ?
— Ике хата бар.

## 9 нчы дәрес

**1.** Исемнәрнең күплек санда тартым белән төрләнешен өйрәнегез.

| | |
|---|---|
| I зат күплек сан<br>(1 лицо мн. число) | карандаш(лар)-**ыбыз**<br>дәфтәр(ләр)-**ебез**<br>хата(лар)-**(ы)быз**<br>бүлмә(ләр)-**(е)без** |
| II зат күплек сан<br>(2 лицо мн. число) | карандаш(лар)-**ыгыз**<br>дәфтәр(ләр)-**егез**<br>хата(лар)-**(ы)гыз**<br>бүлмә(ләр)-**(е)гез** |
| III зат күплек сан<br>(3 лицо мн. число) | карандаш(лар)-**ы**<br>дәфтәр(ләр)-**е**<br>хата(лар)-**ы**<br>бүлмә(ләр)-**е** |

**2.** **Дәреслек, сумка, мәктәп** сүзләрен күплек санда тартым белән төрләндерегез.

**3.** Нокталар урынына тиешле тартым кушымчаларын өстәп языгыз.

1. Минем карандашлар... бик күп, ә синең карандашлар... бармы? 2. 5 нче «А» сыйныф укучылар... контроль эш эшләделәр. 3. Диктантта синең хаталар... аз булган.

**4.** Рәсемнәр урынына сүзләр куегыз. Диалогны үзара сөйләшегез.

— Сәлам, Дима!
— Сәлам, Айнур!
— Кая барасың?

— 

.

— Нәрсә аласың?

—  юк,  алам.

— Минем дә  юк.

— Әйдә бергә барабыз.

— Әйдә.

**5.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәгез. Дустыгыз белән сөйләшегез.



1. — ... ?
   — Безнең мәктәбебез бик зур, яңа.
   — Мәктәбегездә ничә укучы укый?
   — ... .
   — Мәктәбегездә ашханә бармы?
   — ... .

2. — Классыгызда ничә укучы бар?
   — ... .
   — Классыгызда малайлар күпме, кызлар күпме?
   — ... .

## 10–11 нче дәресләр

**1.** Прочитайте диалог, найдите глаголы, выражающие повеление.

— Оля, әйдә бергә дәрес әзерлибез.
— Әйдә, мин риза.
— Син мисал эшлә.
— Ярый, ә син мәсьәлә чиш.

**2. Исегездә калдырыгыз!**

**Боерык фигыль**
Повелительное наклонение

Повелительное наклонение выражает просьбу, повеление, приказ совершить какое-либо действие и имеет формы второго и третьего лица единственного и множественного числа.

**Боерык фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше**
Спряжение глаголов повелительного наклонения

| Барлык формасы (положительная форма) | |
|---|---|
| Берлек санда | |
| I | — |
| II | (син) бар — (ты) иди |
| III | (ул) бар-сы́н — (он) пусть идёт |
| Күплек санда | |
| I | — |
| II | (сез) ба́р-ыгыз — (вы) идите |
| III | (алар) бар-сын-на́р — (они) пусть идут |

| Юклык формасы (отрицательная форма) | |
|---|---|
| Берлек санда | |
| I | — |
| II | (син) ба́р-ма — (ты) не иди |
| III | (ул) ба́р-ма-сын — пусть (он) не идёт |
| Күплек санда | |
| I | — |
| II | (сез) ба́р-ма-гыз — (вы) не идите |
| III | (алар) ба́р-ма-сын-нар — (они) пусть не идут |

**3. Исегездә калдырыгыз!**

Во втором лице множественного числа положительной формы глагола повелительного наклонения ударение падает на первый слог слова: *ба́рыгыз, ки́легез, у́зыгыз*, а также во втором и третьем лице единственного и множественного числа отрицательной формы ударение падает на слог перед аффиксом *-ма, -мә*: *ба́рмагыз, уйна́ма, ки́лмә, җырла́масыннар*.

**4.** Укыгыз һәм, фигыльләрне табып, басымны билгеләгез.

Балалар, вакытында уйнагыз,
Җырлагыз, биегез, көлегез.

М. Җәлил

**5.** Шигырьне укыгыз. Боерык фигыльләрне табып, басым белән әйтегез.

...Әйдәле, Акбай! Өйрән син, арт аягың белән тор.
Аума, аума! Туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!

Г. Тукай



Укы
һәм
тыңла

**6.** Боерык фигыльнең юклык формасы булган вариантны табыгыз.

а) укый ә) әзерләмә б) утыра в) кайта г) килмә

**7.** Рәсемгә карагыз һәм уйлагыз: Ваняга нишләргә кушарсыз?




**8.** Тексттагы фигыльләрне табыгыз, аларны боерык фигыльнең II зат берлек сандагы барлык һәм юклык формаларында (в положительной и отрицательной форме II лица единственного числа повелительного наклонения) языгыз.

Укытучы сыйныфка керде. Укучылар бастылар, укытучыны сәламләделәр. Дежур укучы рапорт бирде. Укытучы дәфтәрләрне таратты. Аннан соң сораулар бирде. Укучылар җавап бирделәр.

Үрнәк: Керде: кер, кермә.
Рапорт бирде: рапорт бир, рапорт бирмә.

**9.** Текст эчтәлеген бер-берегезгә сөйләгез.

**10.** Диалогларны укыгыз, дустыгыз белән сөйләшегез.



1. — Әнием, урамга чыгыйм әле.
— Башта кибеткә бар.
— Ярый, кибеткә барам. Нәрсә алыйм?
— Ипи, сөт ал.

2. — Әни, мин кибеттән кайттым.
— Нәрсә алдың?
— Ипи, сөт алдым. Урамга чыгыйм әле.
— Дәресеңне әзерләдеңме?
— Әзерләдем.
— Ярый, бар, чык.



**11.** Скажите:

— не бегай в классе;
— не кричи в коридоре;
— не шумите на уроке;
— не играй на улице долго;
— не пишите на парте;
— не садитесь на стол.

**12.** Выразите своё согласие или несогласие по поводу предложенных действий.

Кинога бар. Стадионга бар. Телевизор кара. Дустыңны кунакка чакыр. Урамга чык.

## 12 нче дәрес

**1. Исегездә калдырыгыз!**

***Как вежливо попросить что-либо сделать?***

**бар** — иди; **бар әле (ба́рчы)** — иди, пожалуйста
**әйт** — скажи; **әйт әле (ә́йтче)** — скажи, пожалуйста
**бир** — дай; **бир әле (би́рче)** — дай, пожалуйста

**барыгыз әле (ба́рыгызчы)** — идите, пожалуйста
**әйтегез әле (ә́йтегезче)** — скажите, пожалуйста
**бирегез әле (би́регезче)** — дайте, пожалуйста

**2.** Рәсемнәр урынына — сүзләр, нокталар урынына тиешле кушымчалар яки сүзләр куеп укыгыз.

1. Алсу,  бир … . 2. Наил,  күрсәт … . 3. Алсу Галиевна, миңа  бирегез … . 4. Әни, миңа  ал … .

**3.** Дустыгызның үтенеченә (на просьбу) җавап бирегез.

Ү р н ә к : — Кибеткә бар әле.
— Ярар, хәзер барам.

— Миңа булыш әле.
— … .
— Хатамны төзәтче (исправь, пожалуйста, мою ошибку).
— … .
— Рәсем яса әле.
— … .
— Карандаш бир әле.
— … .

**4.** Как попросите у родителей купить:

  

**5.** Бу диалог сезгә ошыймы? Сез аны ничек үзгәртер идегез? Ике диалогны да сәхнәләштерегез.

— Оля, миңа плеер бир әле.
— Юк, бирмим.
— Алайса (тогда) мин синең белән уйнамыйм.
— Мин дә синең белән дус түгел.

**6.** Диалогка төшеп калган репликаларны куегыз, дустыгыз белән сөйләшегез.

— ... ?
— Миңа дәфтәр кирәк иде.
— ... ?
— Шакмаклы дәфтәр. Ничә сум тора?
— 12 сум.
— ... ?
— Миңа 10 дәфтәр бирегез әле.

**7.** Боерык фигыльләрне юклык формасына куеп, җөмләләр төзегез.

Бар, кил, ал, чык, кер, тор, бас, утыр.

## 13–14 нче дәресләр

**1.** Таблицаны өйрәнегез. Нинди сүзләргә — калын, ә нинди сүзләргә нечкә кушымчалар ялгана?

**Хәзерге заман хикәя фигыльләрнең барлык формасында зат-сан белән төрләнеше**
Спряжение глаголов настоящего времени в положительной форме

| Берлек санда | Күплек санда |
|---|---|
| I мин ю-**а-м**, бар-**а-м**<br>II син ю-**а-сың**, бар-**а-сың**<br>III ул ю-**а**, бар-**а** | без ю-**а-быз**, бар-**а-быз**<br>сез ю-**а-сыз**, бар-**а-сыз**<br>алар ю-**а-лар**, бар-**а-лар** |
| I мин сиб-**ә-м**, бир-**ә-м**<br>II син сиб-**ә-сең**, бир-**ә-сең**<br>III ул сиб-**ә**, бир-**ә** | без сиб-**ә-без**, бир-**ә-без**<br>сез сиб-**ә-сез**, бир-**ә-сез**<br>алар сиб-**ә-ләр**, бир-**ә-ләр** |

**2.** Фигыльләргә **мин**, **син**, **ул** алмашлыкларын өстәп языгыз, җөмләләр төзегез.

... укыйм, ... язасың, ... эшли, ... киләм, ... китәм,

... уйный, ... кайтасың, ... утыра, ... белә, ... белмисең, ... сөйли.

**3.** Җөмләләрне дөрес итеп төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| Без дәрестә | мәсьәлә | эшлисең. |
| Син мәктәптә | әнигә | чишәбез. |
| Мин өйдә | мисал | булышам. |

**4.** Тәрҗемә итегез.

1. Ты идёшь, а мы возвращаемся. 2. Вы слушаете, а я говорю. 3. Он повторяет, а я вспоминаю. 4. Я учу стихотворение, а он решает пример. 5. Ты думаешь, а я делаю.

**5.** Укыгыз, фигыльләрне табыгыз, зат-санын билгеләгез.

1. Җәй көне. Эссе һавада мин суда коенам, йөзәм;
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.

Г. Тукай



2.

Берәү,
Икәү,
Өчәү,
Дүртәү...
Санарга өйрәнәбез.
Әллә никадәр сан белеп
Кайтабыз өйләргә без.

Р. Миңнуллин

**6.** Җөмләләрне язып бетерегез.

1. Укытучы укыта, укучы … .
2. Укытучы сорый, укучы … .
3. Укучы диктант яза, укытучы … .
4. Әни әйтә, бала … .

**7.** Как скажете о том, что:

— завтра у вас контрольная работа по математике;
— сегодня вы пишете диктант по татарскому языку;
— вы идёте в библиотеку;
— вы решаете задачу;
— вы играете в футбол?




**8.** Бергәләп көлик!

— Мин юынам, син юынасың, ул юына — кайсы заман була?
— Якшәмбе көн.

## 15–16 нчы дәресләр

**1.** Фигыльләрнең зат-сан белән төрләнешен таблица аша өйрәнегез.

**Хәзерге заман хикәя фигыльләрнең юклык формасында зат-сан белән төрләнеше**
Спряжение глаголов настоящего времени в отрицательной форме

| | Берлек санда | Күплек санда |
|---|---|---|
| I | мин ю-**мый-м** | без ю-**мый-быз** |
| II | син ю-**мый-сың** | сез ю-**мый-сыз** |
| III | ул ю-**мый** | алар ю-**мый-лар** |
| I | мин сип-**ми-м** | без сип-**ми-без** |
| II | син сип-**ми-сең** | сез сип-**ми-сез** |
| III | ул сип-**ми** | алар сип-**ми-ләр** |

**2.** Фигыльләргә **без**, **сез**, **алар** алмашлыкларын өстәп языгыз, җөмләләр төзегез.

... барабыз, ... киләсез, ... чыгалар, ... эшлибез, ... киләсез, ... китәсез, ... уйныйлар, ... ярдәм итәбез.

**3.** Җөмләләрне укыгыз. Хәзерге заман хикәя фигыльләрне табыгыз. Аларны барлык һәм юклык формаларында языгыз.

Ү р н ә к: баралар — бармыйлар.

Җәй көне без урманда ял итәбез. Иртән су коенырга чабабыз. Айдар балык тота, Нәсимә чәчәкләр җыя. Абый гербарий әзерли. Мин җиләк җыям.

**4.** Фигыльләрне барлык һәм юклык формаларында зат-сан белән төрләндерегез.

Килә, яза, ясый, керә, чыга, сөйли, әйтә.

**5.** Фигыльләрне юклык формасына куеп, җөмләләр төзегез.

Бара, килә, сибә, чыга, керә, тора.

**6.** Сообщите матери, что:

— вы не пойдёте в магазин;
— Коля не идёт в школу;
— Наташа не моет посуду;
— вы не читаете книгу;
— вы с другом не идёте на репетицию;
— телевизор не работает.



# 17–18 нче дәресләр

**1.** Таблицаны өйрәнегез.

**Билгеле үткән заман хикәя фигыль**
Прошедшее очевидное время
глагола изъявительного наклонения

| Основа оканчивается: | Аффиксы |
|---|---|
| на гласный или звонкий согласный звук | |
| яз<br>кил<br>аша<br>әзерлә | **-ды**<br>**-де**<br>**-ды**<br>**-де** |
| на глухой согласный звук | |
| кит<br>кайт | **-те**<br>**-ты** |

**2.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Әгәр үткән заман хикәя фигыль сузык һәм яңгырау тартык авазга бетсә, ... . 2. Әгәр үткән заман хикәя фигыль саңгырау тартык авазга бетсә, ... .

**3.** Укыгыз. Үткән замандагы фигыльләрне табыгыз. Алар ничек ясалган? Җөмләләргә сораулар куегыз.

1. Кичә Марат бишле алды, ә Коля дүртле алды. 2. Телевизордан кызыклы кино башланды. 3. Олег өй эшен вакытында эшләде. 4. Лена иртәнге ашны ашады һәм мәктәпкә китте. 5. Аннан соң ул өйгә кайтты, дәресләрен әзерләде.

**4.** Фигыльләрне тиешле алмашлыклар белән языгыз.

... киттем, ... киттең, ... килде, ... әйттем, ... эшләдең, ... сөйләде, ... алдың, ... бирде, ... ашадым, ... әзерләдең.

**5.** Сүзләрне дөрес укыгыз, тәрҗемәсен табыгыз.

[кәйә́ф], [wa°қы́т], [ә̆шлә́мәдә̆], [ŏзá́қ], [қы̆зы̆қлы́], [бә̆т̄ә́], [чирә̆газағы́].

**6.** Сүзләрне төрләндерегез, дәвам итегез.

Минем кәефем, эшем, вакытым.
Синең ... , ... , ... .
Аның ... , ... , ... .

**7.** Сүзләрнең антоним парларын табыгыз, җөмләләр төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| юк | ? | тиз |
| озак | | башланды |
| бетте | | бүген |
| иртәгә | | бар |

**8. Исегездә калдырыгыз!**

по математике — математика**дан**
по татарскому языку — татар телен**нән**
по истории — тарих**тан**
по рисованию — рәсем**нән**

**9.** Диалогны укыгыз, дустыгыз белән сөйләшеп карагыз.

— Олег, нигә кәефең юк?
— Математикадан икеле алдым.
— Ни өчен?
— Өй эшен эшләмәдем.
— Кызганыч...

**10.** Как вы думаете, почему у мальчика нет настроения?



**11.** Җөмләләрне дәвам итегез, сораулар куегыз.

1. Олег — яхшы укучы, чөнки ул … .
2. Петя өй эшен эшләми, шуңа күрә … .

**12.** Хикәяне укыгыз. Ничек уйлыйсыз, хикәягә нинди исем бирергә була?

Бүген Олегның кәефе юк. Ул математикадан икеле алды. Нигә дисеңме? Ул кичә өй эшен эшләмәде. Башта бик озак урамда уйнады. Аннан соң телевизордан кызыклы кино башланды. Кино кичке сәгать унда бетте.

Олег һәрвакыт өй эшен вакытында эшләргә уйлый. Ләкин ул сүзендә тора алмый. Чирек азагы җитә. Математикадан ничәле чыгар? Контроль эштән дә өчле генә булды. Иртәгә тагын контроль эш.



**13.** Ике раслауның кайсы дөрес?

1. Бүген Олегның кәефе бар.
   Олегның кәефе юк.

2. Олег өй эшен эшләп бетерде.
   Олег өй эшен эшләмәде.

3. Олег контроль эштән бишле алды.
   Олег контроль эштән өчле алды.

**14.** Җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз, сөйләргә өйрәнегез.

1. Иртәгә контроль эш. 2. Кичә ул урамда бик озак уйнады, телевизор карады. 3. Математикадан икеле алды. 4. Олегның кәефе юк. 5. Олег өй эшен вакытында эшләми. 6. Тиздән чирек азагы, Олегка математикадан ничәле чыгар?

**15.** Мәзәкне укыгыз. Вадим математиканы нигә начар белә?

— Вадим, нигә син математикадан хәзер начар билгеләр аласың? Дәрескә әзерләнмисеңме әллә? — ди әтисе.

— Юк, әти, мин хәзер Андрей белән утырам. Ул математиканы бик начар белә, — ди улы.



# 19–20 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең дөрес тәрҗемәсен табыгыз, дәфтәрегезгә языгыз.

кызыклы
а) хороший
ә) интересный
б) красивый

чирек
а) урок
ә) четверть
б) перемена

язма эш
а) контрольная работа
ә) самостоятельная работа
б) письменная работа

инде
а) ещё
ә) уже
б) сейчас

**2.** Җөмләләрнең дөрес тәрҗемәсен табыгыз.

Олег өй эшен вакытында эшләми.
1. Олег не может выполнить домашнее задание вовремя.
2. Олег делает домашнее задание вовремя.
3. Олег не делает домашнее задание вовремя.

Иртәгә тагын контроль эш.
1. Завтра снова контрольная работа.
2. Сегодня снова самостоятельная работа.
3. Завтра снова самостоятельная работа.

**3.** Хикәя эчтәлегенә туры килмәгән җөмләне табыгыз, дәфтәрегезгә языгыз.

1. Олег математикадан бишле алды. 2. Ул өй эшен эшләмәгән иде. 3. Телевизордан кызыклы кино башланды.

**4.** Ике раслауның кайсы дөрес?

1. Олег өй эшен вакытында эшли.
   Олег өй эшен вакытында эшләми.

2. Олег контроль эшне яхшы эшләде.
   Олег контроль эшне начар эшләде.

**5.** Хикәянең эчтәлегенә кайсы исем күбрәк туры килә?

1. Олегның кәефе юк. 2. Олег сүзендә тора алмады. 3. Ялкау укучы. 4. Олег уйнарга ярата. 5. Олег — начар укучы.

**6.** Хикәядәге 1 нче һәм 2 нче җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз.

**7.** Диалогларны дустыгыз белән сөйләшегез.

1. — Олег, әйдә урамга уйнарга чыгабыз.
   — Ә син өй эшләрен эшләдеңме?
   — Юк әле.
   — Әйдә башта өй эшләрен эшлибез, аннан соң чыгабыз.

2. — Олег, әйдә уйнарга чыгабыз.
   — Юк, мин чыкмыйм.
   — Ни өчен?
   — Мин дәрес әзерлим.

**8.** Узнайте у друга:

— какие отметки он сегодня получил;
— сколько уроков было;
— какой был первый урок;
— писали ли они диктант;
— есть ли у него тетрадь в клетку.

**9.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Олегның нигә кәефе юк?
2. Ул математикадан нинди билгеләр ала?
3. Чирек азагы кайчан?
4. Олегка математикадан ничәле чыгар?

**10.** Әйтик, Олег яхшы укучы, ди. Ул өй эшләрен вакытында эшли. Хикәя ничек үзгәрер? Үз вариантыгызны язып карагыз.

**11.** Үзегез язган хикәянең эчтәлеген сөйләргә өйрәнегез.

## 21–22 нче дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

**Сан**
Имя числительное

Имя числительное обозначает количественный признак предметов: биш (китап), өч (дәрес).

В татарском языке имена существительные при числительных употребляются в единственном числе: өч укучы, бер китап, ун дәфтәр.

**Количественные (микъдар) числительные** отвечают на вопрос **ничә?** и обозначают количественный признак предметов: өч укучы, бер китап, ун дәфтәр.

**Порядковые (тәртип) числительные** отвечают на вопрос **ничәнче?**, имеют аффиксы **-ынчы/-енче, -нчы/-нче**: унынчы, сигезенче, алтынчы, җиденче. Обозначают порядок предметов при счёте.

**Собирательные (җыю) числительные** отвечают на вопрос **ничәү?** и обозначают совокупность предметов. Данный разряд числительных не имеет определяемого слова и образуется только в пределах десяти: берәү, икәү, өчәү, ..., унау.

2. Саннарны сүз белән языгыз.

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11 — ... | 20 — ... | 80 — ... | 1000 — ... |
| 12 — ... | 30 — ... | 90 — ... | 2000 — ... |
| 13 — ... | 40 — ... | 100 — ... | 3000 — ... |

3. Тәрҗемә итегез.

15 яблок, 12 книг, 10 тетрадей, 2 кг апельсинов, 5 кг муки, 16 учеников, 8 девочек, 9 мальчиков.

**4.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны өстәп, 7, 28, 29, 30, 31, 365 саннарын кулланып, җөмләләр төзегез.

Бер атна...
Бер ай... ? көн.
Бер ел...

**5.** Рәсемгә карагыз һәм әйтегез: салават күперендә ничә төс бар? Алар нинди?



**6.** Саннарны сүз белән языгыз, җөмләләр төзегез.

10, 20, 30, 40, 50, 60, 70, 80, 90, 100, 1000

**7.** Саннарны дөрес әйтергә өйрәнегез.

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
| 111 | 112 | 113 | 114 | 115 | 116 | 117 | 118 | 119 |

! **8. Исегезгә төшерегез!**

**мәсьәлә** — задача; **мисал** — пример
**кушарга** — прибавить; **тапкырларга** — умножать
**алырга** — вычитать; **бүләргә** — делить

**9.** Скажите другу:

— сколько вам лет;
— в какой школе вы учитесь;
— в каком ряду вы сидите;
— сколько мальчиков и девочек в классе;
— что вам надо пять тетрадей в клетку и пять тетрадей в линейку.

**10.** Какой вопрос зададите, чтобы узнать:

— сколько человек у них в семье;
— сколько комнат у них в квартире;
— в каком классе учится Марат;
— сколько книг прочитал Марат летом;
— в каком ряду сидит Марат?

**11.** Дәресләр расписаниесен дәвам итегез.

Беренче дәрес — математика. Икенче дәрес — ... .




**12.** Мәзәкне укыгыз, ошаса, сөйләргә өйрәнегез.



Укытучы беренче сыйныф укучысыннан:
— Бишкә берне кушсаң (если прибавишь), ничә була? — дип сорый.
Малай эндәшми.
— Алайса тыңла. Әйтик, башта мин сиңа биш алма, аннары бер алма бирәм. Шуннан соң ничә алмаң була?
— Җиде.
— Ничек?
— Чөнки минем кесәдә (в кармане) бер алма бар инде.

# МИН — ӨЙДӘ БУЛЫШЧЫ

## 23–24 нче дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

Когда мы обращаемся к родителям ласково, с любовью, то говорим: **әткәй, әнкәй, әбекәй, бабакай.**

**2.** Таблицаны үрнәк буенча дәвам итегез, дәфтәрегезгә языгыз.

| Ничә? | Ничәнче? |
|---|---|
| бер | беренче |
| ике | ... |
| өч | ... |
| дүрт | ... |
| биш | ... |

**3.** Шигырьне укыгыз. Гаиләдә ничә кеше?



**Безнең гаилә**

Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи —
Безнең өйдә без җидәү: безнең песи — җиденчесе.
Бергә ашый, чәй эчә, безнең белән бергә йоклый ул,
Хезмәте дә бар, өйне тычкан явыздан саклый ул.

Г. Тукай

**җидәү** — семеро **явыз** — злой

**4.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Гаиләдә ничә кеше бар? 2. Алар кемнәр? 3. Песи ничәнче? 4. Гаиләдә песинең нинди хезмәте бар?

**5. Исегезгә төшерегез!**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **минем** | абыем | апам | әнием | бабам |
| **синең** | абыең | апаң | әниең | бабаң |
| **аның** | абыйсы | апасы | әнисе | бабасы |

**6.** Помогите буквам **ә, е** найти свои места.

Б...зн...ң гаил... бик зур. Гаил...дә алты к...ш...: ...ти, ...ни, апа, абый, эн...м һ...м мин.

**7.** Диалогка төшеп калган репликаларны өстәгез.

— Оля, сезнең гаиләдә кемнәр бар?
— ... .
— Әниең кайда эшли?
— ... .
— Минем әтием заводта эшли. Ә синең әтиең кайда эшли?
— ... .

**8. Исегездә калдырыгыз!**

1. **-чы/-че** — словообразовательный аффикс, который, присоединяясь к основе, образует названия профессий:
эш (работа) — эш**че** (рабочий),
җыр (песня) — җыр**чы** (певец),
балык (рыба) — балык**чы** (рыбак).
2. Если хочешь сказать кто кем работает, то говоришь:
**Минем әнием — сатучы.** — Моя мама — продавщица.
**Минем әнием сатучы булып эшли.** — Моя мама работает продавщицей.

**9.** Сүзләрдән профессия исемнәре ясагыз. Сүзләрне тәрҗемә итегез, җөмләләр төзегез.

Бакча, балык, тимер, тегү, төзү, китапханә, тәрбия.

**10.** Кем работают твои родственники? Продолжите.

1. Минем әтием ... . 2. Минем әнием ... . 3. Минем апам ... . 4. Минем абыем ... .

**11.** Рәсемнәргә карап, профессия исемнәрен әйтегез.




**12.** Ул кем?

1. Ул мәктәптә укыта. 2. Ул кибеттә ашамлыклар сата. 3. Ул бакчада яшелчәләр үстерә. 4. Ул матур күлмәкләр тегә. 5. Ул яхшы хикәяләр яза. 6. Ул шәһәрдә йортлар төзи.

**13.** Спросите у соседа по парте:

— сколько человек у него в семье;
— есть ли у него сестра, брат;
— есть ли у него дедушка, бабушка;
— кем работает его папа (мама, бабушка, дедушка).

**14.** Рәсемнәрне карагыз. Болар нинди һөнәр ияләре?



**15.** Сезнең гаиләдә кемнәр бар? Алар кайда эшли? Алар кем булып эшли?

## 25–26 нчы дәресләр

**1.** Рәсемнәргә карап, вакытны дөрес әйтергә өйрәнегез.

сәгать 6 — 6 часов

сәгать 6 да — в 6 часов

6 сәгать 10 минут — 6 часов 10 минут

6 сәгать 10 минутта — в 6 часов 10 минут

сигезенче ярты — половина восьмого

сигезенче яртыда — в половине восьмого

биш минуттан җиде тула — без пяти минут семь



**2. Исегездә калдырыгыз!**

**Сәгать ничә?** — Который час?
**Сәгать алты.** — Шесть часов.
**Сәгать ничәдә?** — В котором часу?
**Сәгать алтыда.** — В шесть часов.

**3.** Тәрҗемә итегез.

1) сәгать җиде — ...
сәгать җиденче ярты — ...
сәгать җидедә — ...
сәгать җиденче яртыда — ...

2) иртә — ...
дәресләр башлана — ...
иртәнге аш — ...
иртән — ...
дәресләр бетә — ...
кичке аш — ...

**4.** Дөрес тәрҗемәне табыгыз.

| | |
|---|---|
| йокыдан тору | подготовка уроков |
| дәресләр | обед |
| төшке аш | отдых |
| ял итү | занятия в школе |
| дәрес әзерләү | подъём |
| кичке аш | сон |
| йокы | ужин |

**5.** Җөмләләрне укыгыз. 1 нче һәм 2 нче баганалардагы (в столбиках) фигыльләрнең кушымчаларын чагыштырыгыз. Алар нәрсә белән аерылалар?

| | |
|---|---|
| Рәсим тора. | Рәсим торды. |
| Рәсим юына. | Рәсим юынды. |
| Рәсим ашый. | Рәсим ашады. |
| Нәсим зарядка ясый. | Нәсим зарядка ясады. |
| Нәсим мәктәпкә китә. | Нәсим мәктәпкә китте. |

| | |
|---|---|
| Нәсим мәктәптән кайта. | Нәсим мәктәптән кайтты. |
| Нәсим урамга чыга. | Нәсим урамга чыкты. |
| Нәсим урамда уйный. | Нәсим урамда уйнады. |

**6.** Расположите рисунки по порядку режима дня. Расскажите о своём режиме дня.




**7.** Скажите, что:

— ваша мама встаёт в 6 часов утра;
— вы обедаете в 11 часов 15 минут;
— братишка приходит из школы в 2 часа дня;
— вы ужинаете в 7 часов вечера.

**8.** Спросите у друга:

— во сколько часов он встаёт утром;
— делает ли он зарядку;

— во сколько часов начинаются уроки в школе;
— во сколько часов заканчиваются уроки.



**9.** Как вы спросите у прохожего время? Выберите лучший вариант.
— Хәзер сәгать ничә?
— Әйтегезче, зинһар, вакыт күпме?
— Гафу итегез, сәгать ничә?

## 27–29 нчы дәресләр

**1.** Билгеле үткән заман хикәя фигыльләрнең зат-сан белән төрләнешен өйрәнегез.

**Билгеле үткән заман хикәя фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше**

Спряжение глаголов прошедшего определённого времени

| Барлык формасы | | |
|---|---|---|
| | Берлек санда | Күплек санда |
| I | мин булыш-**ты-м** | без булыш-**ты-к** |
| II | син булыш-**ты-ң** | сез булыш-**ты-гыз** |
| III | ул булыш-**ты** | алар булыш-**ты-лар** |
| I | мин ю-**ды-м** | без ю-**ды-к** |
| II | син ю-**ды-ң** | сез ю-**ды-гыз** |
| III | ул ю-**ды** | алар ю-**ды-лар** |
| I | мин сөрт-**те-м** | без сөрт-**те-к** |
| II | син сөрт-**те-ң** | сез сөрт-**те-гез** |
| III | ул сөрт-**те** | алар сөрт-**те-ләр** |

| Юклык формасы | | |
|---|---|---|
| | Берлек санда | Күплек санда |
| I<br>II<br>III | мин булыш**-ма-ды-м**<br>син булыш**-ма-ды-ң**<br>ул булыш**-ма-ды** | без булыш**-ма-ды-к**<br>сез булыш**-ма-ды-гыз**<br>алар булыш**-ма-ды-лар** |
| I<br>II<br>III | мин сөрт**-мә-де-м**<br>син сөрт**-мә-де-ң**<br>ул сөрт**-мә-де** | без сөрт**-мә-де-к**<br>сез сөрт**-мә-де-гез**<br>алар сөрт**-мә-де-ләр** |

**2.** **Бар**, **кил** фигыльләрен зат-сан белән төрләндерегез.

**3.** Бирелгән ситуацияләргә карата риза булуны (согласие) яки риза булмауны (несогласие) белдерегез.

Үрнәк: — Мин өйдә булыштым.
— Әйе, мин өйдә булыштым.
— Юк, мин өйдә булышмадым.

1. Мин физзарядка ясадым.
…
…

2. Мин кибеткә бардым.
…
…

3. Мин кибеттән кайттым.
…
…

4. Мин аш пешердем.
…
…

5. Мин бишле алдым.
…
…

6. Мин идән юдым.
…
…

**4.** Сүзләрнең тәрҗемәсен сүзлекләрдән табыгыз, истә калдырыгыз.

тузан сөртә — …

идән себерә — …

тузан суыртa — ...
кер үтүкли — ...
чүп чыгара — ...
сеңлесен (энесен) карый — ...
аш пешерә — ...
урын җыя — ...
идән юа — ...



**5.** 4 нче күнегүдәге фигыльләрне билгеле үткән заман хикәя фигыль формасына куегыз.

**6.** Рәсемнәргә карагыз һәм әйтегез: малай нишли?



**7.** **Җый, үтүклә, сөрт** фигыльләрен билгеле үткән заман хикәя фигыль формасында кулланып, җөмләләр төзегез.

**8.** Әйтик, рәсемдәге малайның исеме — Костя. Ул нишләде?

**9.** Костяга рәсемдәге эшләрне эшләргә кушыгыз.

**10.** Рәсемнәрдә күрсәтелгән эшләрне башкару турында диалог төзегез.

11. Сообщите другу о том, что:

— вы открыли форточку;
— вы помыли полы;
— у вас в квартире чисто.

12. **Исегездә калдырыгыз!**

**Слова одобрения**

**яхшы** — хорошо; **ярый** — ладно
**бик яхшы, бик әйбәт** — очень хорошо

13. Допустим, твой друг вынес мусор, помыл посуду, сходил в магазин. Как вы одобрите его дела?

## 30–31 нче дәресләр

1. Сүзләрне дөрес укырга өйрәнегез, тәрҗемә итегез.

[йŏқŏ́], [ŏза́қ], [қŏйма́қ], [hə́рwақы́т].

2. Как изменятся глаголы, если действия происходят:

а) в настоящем времени;
б) в прошедшем времени?

Действия: тор, юын, җыйма, әзерлә, эчмә, әйт, кит.



3. Укыгыз һәм әйтегез: сез кемгә охшар идегез (на кого хотели бы быть похожим)?

1. Рәсим йокыдан торды. Озак юынды. Урын-җирне җыймады.

Әнисе бик тәмле итеп ашарга әзерли. Өстәлдә — коймак белән чәй. Алар бергә чәй эчтеләр. Рәсим әнисенә рәхмәт әйтте, аннан соң мәктәпкә китте.



2. Илнур һәрвакыт иртә тора. Юына, киенә, урын-җирне җыя. Ул кухняда әнисенә булыша: ипи кисә, өстәлгә тәлинкәләр, кашыклар куя. Нинди рәхәт әни белән бергә чәй эчү! Аннан соң Илнур мәктәпкә китә.

**4.** Ике раслауның кайсы дөрес?

1. Илнур һәрвакыт урын-җирне үзе җыя.
   Рәсим һәрвакыт урын-җирне үзе җыя.

2. Рәсим әнисенә булышты.
   Илнур әнисенә булышты.

3. Илнур ипи кисмәде, тәлинкәләр, кашыклар куймады.
   Рәсим ипи кисмәде, чәй әзерләмәде.

**5.** Берегез укыгыз, икенчегез тыңлагыз. Икенче җөмләдәге аерманы табыгыз.

1. Рәсим иртә торды.
   Илнур иртә тора.

2. Илнур урынын үзе җыя.
   Рәсим урынын үзе җыймый.

3. Илнур чәй әзерли.
   Рәсим чәй әзерләми.

**6.** Бирелгән фигыльләрне хәзерге һәм билгеле үткән заманда барлык һәм юклык формаларында зат-сан белән төрләндерегез.

Булыш, ю, җый, ал, киен, кис.

Ү р н ә к : Булыш — булыша, булышмый, булышты, булышмады.

**7.** Хикәяләрне I зат исеменнән сөйләп карагыз.

## 32–33 нче дәресләр

**1.** Тиешле фигыльләрне куеп, таблицаны тутырыгыз.

| Илнур нишли? | Рәсим нишли? |
|---|---|
| урынын ...<br>ипи ...<br>тәлинкә ...<br>кашык ... | урынын ...<br>ипи ...<br>тәлинкә ...<br>кашык ... |

**2.** **Исегездә калдырыгыз!**

**Кереш сүзләр**
Вводные слова

**Минемчә** — по-моему; **минем фикеремчә, минем уйлавымча** — по моему мнению; **әлбәттә** — конечно; **кызганычка каршы** — к сожалению; **бәхеткә каршы** — к счастью; **киресенчә** — наоборот.

**3.** Бу сүзләрне дөрес укыйсызмы?

Тырыш [тырыш], ихтирамлы [ихтыйрамлы], ихтирамсыз [ихтыйрамсыс], тәрбияле [тәрбийәлә], ярдәмчел [йәрдәмчәл].

**4.** Кереш сүзләрне кулланып, Рәсимгә һәм Илнурга бәя бирегез.

Терәк сүзләр: эшчән, начар, тырыш, әйбәт, ялкау, ихтирамсыз, ихтирамлы, тәрбияле, ярдәмчел.

**5.** Җөмләләрне тәгалләгез.

1. Илнур — ... малай, чөнки ... .
2. Рәсим — ... малай, чөнки ... .

**6.** Илнурны мактагыз. Рәсимгә киңәшләр бирегез.

**7.** Илнур белән Рәсим турындагы хикәяләрне үзегез теләгәнчә үзгәртеп языгыз. Язган хикәяләрне бер-берегезгә сөйләгез.

**8.** Таблицаны тутырыгыз.

| Содержание речевых действий | Речевой образец | Граммати-ческая форма глагола |
|---|---|---|
| Как сказать о том, что вы делаете в данный момент? | ... | ... |
| Как сказать о том, что вы уже сделали? | ... | ... |
| Как выразить повеление? | ... | ... |
| Как выразить просьбу? | ... | ... |
| Как похвалить? | ... | ... |

**9.** Спросите у друга:

— рано ли он встаёт;
— убирает ли он постель;
— во сколько часов он встаёт утром;
— во сколько часов возвращается из школы;
— помогает ли он дома маме.

## 34–35 нче дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

**Инфинитив**

Инфинитив отвечает на вопросы *что делать? что сделать?* **(нишләргә?)**, *что не делать? что не сделать?* **(нишләмәскә?)** и образуется в положительной форме присоединением к основе на гласный звук аффиксов **-рга/-ргә**, к основе на согласный звук аффиксов **-ырга/-ергә, -арга/-әргә**, к основе из одного слога, оканчивающейся на **й**, **и**, аффиксов **-ярга/-яргә.**

Инфинитив в речи часто употребляется со словами: **кирәк** — надо; **кирәкми** — не надо; **ярый** — ладно, можно; **ярамый** — нельзя, невозможно; **мөмкин** — можно; **мөмкин түгел** — невозможно, нельзя; **тиеш** — должен; **тиеш түгел** — не должен; **була** — можно; **булмый** — нельзя.

Правила присоединения аффиксов, образующих инфинитив, к основе глагола

| Глаголы | Аффиксы | Примеры |
|---|---|---|
| Глаголы с основой, оканчивающейся на **гласный** | **-рга/-ргә** | **аша-рга** — кушать<br>**сөйлә-ргә** — рассказывать |
| Глаголы с основой из 2–3-х слогов, оканчивающейся на **согласный** | **-ырга/-ергә** | **булыш-ырга** — помочь<br>**өйрән-ергә** — научиться |
| Глаголы с основой из одного слога, оканчивающейся на **р, л** | **-ырга/-ергә** | **бар-ырга** — идти<br>**кил-ергә** — прийти |
| Глаголы с основой из одного слога, оканчивающейся на согласные, кроме **р, л, й** | **-арга/-әргә** | **яз-арга** — писать<br>**бас-арга** — встать<br>**өз-әргә** — рвать<br>**үс-әргә** — расти |
| Глаголы с основой из одного слога, оканчивающейся на **й, и** | **-ярга/-яргә** | **җый** — **җыярга** — собирать<br>**ки** — **кияргә** — надевать |

**2.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны өстәп языгыз.

1. Әни, урамга чы(к)... мөмкинме?
2. Эш беткәч, уйна... ярый.
3. Гөлләргә еш су си(п)... ярамый.
4. Кич безгә Радик кил... мөмкин.
5. Өйдә әнигә булыш... кирәк.
6. Савыт-сабаларны ю... кирәк.

**3.** **Ярый**, **ярамый**, **кирәк**, **кирәк түгел** сүзләрен кулланып, җөмләләр төзегез.

**4.** Рәсим турында хикәяне исегезгә төшерегез. Инфинитив формасын һәм **кирәк**, **ярамый** сүзләрен кулланып, аңа киңәшләр бирегез.

Үрнәк: Рәсим бик озак юына.
Рәсим, тиз юынырга кирәк.

1. Урын-җирен җыймый.
   ...
2. Әнисенә иртән булышмый.
   ...
3. Мәктәпкә соңга кала.
   ...

**5.** Как скажете о том, что:

— утром надо убирать постель;
— зубы надо чистить каждый день;
— утром надо делать зарядку;
— нельзя опаздывать на урок;
— нельзя бегать в классе;
— нельзя шуметь на уроке?

**6.** Сообщите о том, что мама велела вам:

— сходить в магазин;
— купить молоко, хлеб;
— вынести мусор;
— подмести полы.

**7.** Спросите у друга, велела ли его мама:

— сходить в магазин;
— купить молоко, хлеб;
— вынести мусор;
— подмести полы.

**8.** Төшеп калган сүзләрне куеп, сорауларга җавап языгыз: сез кемгә нишләргә булышасыз?

Мин ...гә ... ... булышам.
Мин ...га ... ... булышам.
Мин ...кә ... ... ярдәм итәм.
Мин ...ка ... ... ярдәм итәм.

**9.** Спросите у друга, помогает ли он маме:

— мыть полы;
— пылесосить;
— поливать цветы;
— выносить мусор.

**10.** Попросите друга помочь вам:

— готовить уроки;
— гладить бельё;

— решить примеры;
— купить продукты.

**11.** Диалогны дәвам итегез.

— Син әниеңә булышасыңмы?
— Әйе, булышам.
— Нишләргә булышасың?
— ... .

**12.** Как скажете о том, что вы помогаете маме:

— чистить картошку;
— убирать комнату;
— накрывать на стол?

**13.** Как скажете, если ваш друг помог:

— составить диалог;
— готовить уроки;
— решить задачу;
— написать сочинение?



# 36–37 нче дәресләр

**1.** Хикәяне укыгыз. Ләйлә белән Наил әниләренә ничек булыштылар?



Менә кич житте. Әниләре эштән кайтты. Өй чиста. Кибеткә барырга кирәкми. Өстәлдә әзер аш. Чәй дә кайнаган.

Әниләре:

— Менә рәхмәт, балалар. Кем эшләде моны? — дип сорады.

Ләйлә белән Наил бер-берсенә карап елмайдылар.

**кайнаган** — вскипел
**бер-берсенә** — друг на друга
**елмайдылар** — улыбнулись

**2.** Җөмләләрне тутырып языгыз.

Наил кибеткә ... . Ләйлә чәй ... . Әниләре эштән ... . Әниләре балаларны ... . Ләйлә белән Наил ... .

**3.** **Исегездә калдырыгыз!**

**Ничек мактарга?** — Как похвалить?

*Булдыргансың!*
*Шәп булган!*
*Нинди эшчән малай (кыз)!*
*Бик яхшы!*

**4.** Восстановите диалоги. Выберите реплику, выражающую похвалу.

— Әни, без өйне җыештырдык.
— ...

1. Шулаймы?
2. Менә булдыргансыз.
3. Кайчан?
4. Син яхшы эшләгәнсең.

— Абый, мин кибеткә бардым.
— ...

1. Чынлапмы?
2. Кайсы кибеткә?
3. Син эшчән.
4. Яхшы булган.

**5.** Допустим, ваш друг говорит о своих хороших поступках. Его надо похвалить. Составьте диалог и поговорите друг с другом.

**6.** Әйтик, Наил Ләйләгә:

— кибеткә барырга;
— гөлләргә су сибәргә;
— идән юарга куша.

Ул ничек әйтер?

**7.** 1 нче күнегүдәге хикәядән үткән заман хикәя фигыльләрне табыгыз, аларны хәзерге заман формасында языгыз.

**8.** Бу бәяләмәләрнең кайсы Наил белән Ләйләгә туры килә? Аларны кулланып, Наил белән Ләйләне мактагыз.

Тыйнак, ялкау, эшчән, тыңлаучан, начар, әти-әниләрен яраталар, мактанчык, ихтирамлы, мактанчык түгел, үзара дус.

**9.** 1 нче күнегүдәге хикәягә охшаган хикәя языгыз.

## 38–39 нчы дәресләр

**1.** Сүзләрне дөрес укыгыз.

[йәрдә́м итәргә́], [ŏлó], [кә̆чә́], [булы̆шы̆рға́], [қы̆зы̆қлы́], [йаºны̆на́], [чы̆қты́], [бŏзŏла́], [чаºқы̆рды́], [аºшады́м], [ирнә̆ңдә́], [сәйәхә́т итә́], [китабы́н].

**2.** Сүзләрнең антоним парларын табыгыз, җөмләләр төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| керде | ? | җавап бирде |
| олы | | ялкау |
| ерак | | кече |
| сорады | | якын |
| тырыш | | чыкты |

**3.** Нокталар урынына тиешле килеш кушымчаларын һәм кирәкле фигыльләрне куеп языгыз.

Әни кухня... керде. Оля бүлмәгә ... .
Әни кухня... эшләде. Оля бүлмәдә ... .
Әни кухня... чыкты. Оля бүлмәдән ... .

**4.** Как скажете о том, что вы:

— думали помочь матери;
— хотели помочь матери;
— не хотели помочь матери;
— думали мыть посуду;
— не хотели мыть посуду;
— не думали мыть посуду?

**5.** Диалогка төшеп калган репликаларны куегыз, дустыгыз белән сөйләшеп карагыз.

— ... ?
— Әйе, мин өйдә.
— ... ?
— Китап укыйм.
— ... ?
— Әйе, бик кызык китап.

**6. Исегездә калдырыгыз!**

**минем өчен** — для меня
**синең өчен** — для тебя
**аның өчен** — для него
**үзе өчен** — для себя
**безнең өчен** — для нас
**сезнең өчен** — для вас
**алар өчен** — для них

**7.** Җәя эчендәге сүзләрне тәрҗемә итегез һәм нокталар урынына куеп языгыз.

Бу чәчәк ... (для кого?)?
Бу чәчәк ... (для меня).
Бу чәчәк ... (для тебя).
Бу чәчәк ... (для него, неё).



**8.** Хикәяне укыгыз. Иң яхшы укучыга бәя бирегез. Таблицаны кулланыгыз.

## Ике пирожный

Әниләре бүлмәгә керде дә кызларын үзенә ярдәм итәргә чакырды. Олы кызы Наташа китап укый, ә кече кызы Оля рәсем ясый иде. Оля әнисенә булышырга уйлады һәм кухняга керде.

— Бер генә бит укыйм да мин дә булышам. Шундый кызыклы китап! — диде Наташа.

Оля барлык савыт-сабаны юды һәм Наташа янына чыкты, булышырга чакырды.

— Мин өйдә юк. Африкада сәяхәт итәм. Анда пальмалар, попугайлар...



Оля яңадан кухняга керде. Тиздән ул эшен бетерде һәм рәсем ясый башлады. Наташа да китапны укып бетерде.



— Менә мин өйдә. Ә синең иреңеңдә нәрсә ул? — дип сорады Наташа.

— Крем. Мин ике пирожный ашадым. Берсе — үзем өчен, ә икенчесе — синең өчен.

— Ә нигә минем өчен? — дип гаҗәпләнде Наташа.

— Син бит Африкада. Африка бик ерак бит, шуңа күрә кремлы пирожный бозыла дип уйладык, — дип җавап бирде Оля.

Ю. Ермолаевтан

**сәяхәт итәм** — путешествую  **яңадан** — снова
**бозыла** — портится

| Ничек укый? | Авазларны ничек әйтә? | Интонациясе |
|---|---|---|
| Кычкырып укый.<br>Кычкырып укымый.<br>Дөрес укый.<br>Тиз укый.<br>Әкрен укый.<br>Бик әкрен укый. | Авазларны дөрес әйтә.<br><br>Авазларны дөрес әйтми. | Дөрес интонация белән укый.<br><br>Дөрес интонация белән укымый. |

**9.** Хикәядән планга туры килгән абзацларны табып укыгыз.

1. Әниләре кызларны ярдәмгә чакырды.
2. Оля булышырга уйлады һәм савыт-сабаны юа башлады.
3. Наташа «Африкада».
4. «Ә синең иренеңдә нәрсә ул?» — дип сорады Наташа.
5. «Кремлы пирожный бозыла», — диде Оля.

**10.** Ике раслауның кайсы дөрес? Дөрес вариантны дәфтәрегезгә языгыз.

1. Кызлар әниләренә ярдәм итәргә теләмәделәр.
   Оля әнисенә ярдәм итәргә теләде.

2. Оля кызыклы китап укый.
   Оля савыт-саба юды.

3. Наташа китапны укып бетерде.
   Оля рәсемне ясап бетерде.

4. Наташа бер пирожный ашады.
   Оля ике пирожный ашады.

**11.** Җөмләләрне дәвам итегез, дәфтәрегезгә языгыз.

1. Олы кызы Наташа китап ... .
2. Бер бит кенә укыйм да ... .
3. Берсе — үзем өчен, ... .
4. Африка ... .
5. Кремлы пирожный ... .

**12.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Кызларның әниләре кухняда нәрсә пешерә?
2. Оля белән Наташа нишлиләр?
3. Әниләре кемне ярдәмгә чакырды?
4. Наташа ярдәм иттеме?
5. Кем ярдәм итте?

## 40–41 нче дәресләр

**1.** Диалогларны текст эчтәлеге буенча урнаштырыгыз. Кем сөйләме икәнен ачыклагыз.

1. — Апа, әйдә әнигә булышыйк, — диде … .
— Бер генә бит укыйм да булышам, — диде … .
2. — Балалар, мин пирожный пешерәм, әйдәгез булышыгыз, — диде … .
— Хәзер, әни, — диде … .
— Шундый кызыклы китап, бер генә бит укыйм инде, — диде … .

3. — Апа, мин савыт-сабаны юдым, әйдә азрак булыш инде, — диде … .
— Мин Африкада сәяхәт итәм, — диде … .

4. — Ә миңа пирожный кайда? — диде … .
— Син Африкада. Африка ерак бит. Кремлы пирожный бозылыр дип уйладык, — диде … .

**2.** Хикәянең эчтәлегенә карата сораулар төзегез.

**3.** Хикәяне сәхнәләштерегез. Иң яхшы уйнаучыны билгеләгез.

**4.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Оля әнисенә ничек ярдәм итте?
2. Наташа ни өчен «Мин өйдә юк, мин Африкада», — диде?
3. Оля эшен бетергәч нишләде?

**5.** Җөмләләрне дәвам итегез, дәфтәрегезгә языгыз.

1. Олы кызы Наташа китап … .
2. Бер бит кенә укыйм да … .
3. Африка бик ерак бит, шуңа күрә … .

**6. Исегезгә төшерегез!**

Вводные слова **(кереш сүзләр)** употребляются для выражения отношения говорящего к действию:
**минемчә** — по-моему,
**минем фикеремчә, минем уйлавымча** — по моему мнению,
**синеңчә** — по-твоему.




**7.** Диалогны укыгыз, кереш сүзләрне табыгыз.

— Кичә Слава математикадан тагын икеле алган.

— Минем фикеремчә, ул бик ялкау малай.

— Ул бик озак авырды. Минемчә, аңа ярдәм итәргә кирәк.

**8.** Кереш сүзләрне кулланып, түбәндәге вакыйгаларга (событиям) үз фикерегезне белдерегез.

1. Кичә концерт бик матур булды.
2. Җәй көне шәһәрдә бик күңелле.
3. Татарча сөйләшергә өйрәнү бик авыр.
4. Татарча сөйләшергә өйрәнү бик җиңел.

**9.** Ничек уйлыйсыз: ике пирожныйны ашап, Оля дөрес эшләдеме? Нокталар урынына кереш сүзләр куегыз.

1. ... , Оля дөрес эшләде, чөнки Наташа булышмады.
2. ... , Оля дөрес эшләмәде, чөнки Наташа аның апасы.
3. ... , Оля дөрес эшләде, чөнки Наташа савыт-саба юмады.

**10.** Нокталар урынына тиешле сүзләрне куеп языгыз.

— Минемчә, Оля — ... кыз.

— Минем уйлавымча да, Оля ... .
— Ә Наташа?
— Минем фикеремчә, Наташа ... .
— Әйе, мин дә шулай уйлыйм.
— Кызлар нинди?
— ... .

**11.** Рәсемнәргә карап, хикәянең эчтәлеген үзгәртеп языгыз.



**12.** Үзегез төзегән хикәяне рольләргә бүлеп сәхнәләштерегез, «актёр»ларга бәя бирегез. Иң яхшы хикәяне сайлап алыгыз.

**13.** Наташа һәм Оля турындагы ике хикәянең сезгә кайсы ошады? Сорауларга җавап бирегез.

1. Кайсы хикәядә кызлар дус?
2. Кайсы хикәядә әнигә күңеллерәк?
3. Кайсы хикәядә гаилә тату?

**14.** Үзегез төзегән хикәяне сөйләргә өйрәнегез.

# ДУСЛАР БЕЛӘН КҮҢЕЛЛЕ



## 42–43 нче дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**

**дус** — друг
**чын дус** — настоящий друг
**дуслык** — дружба
**дуслаштык** — подружились

**2.** Рәсемгә карап, җөмләләрне тәмамлагыз. Нокталар урынына сүз куйганда, 1 нче күнегүне файдаланыгыз. Кызлар дуслармы?



Рәмзия, Фәйрүзә, Светлана … .
Ә Наташа … .



Нәфисә Светланадан … .
Светлана … .
Нәфисә белән Светлана … .
— Әйдә … .
— Мин риза.

**3.** Төрләнешне дәвам итегез.

| | |
|---|---|
| Минем дустым. | Безнең … . |
| Синең … . | Сезнең … . |
| Аның … . | Аларның … . |

**4.** Диалогларга кирәкле репликаларны өстәгез, дустыгыз турында сөйләгез.

1. — ... ?
— Әйе, минем дустым бар.
— Ул ничәнче сыйныфта укый?
— ... .

2. — Әйдә дуслашабыз.
— Мин риза.
— Син кайда торасың?
— ... . Ә син?
— ... . Син ничәнче сыйныфта укыйсың?
— ... . Ә син?
— ... .

**5.** Предложите другу:

— вместе поиграть;
— вместе готовить уроки;
— вместе пойти в школу.

**6.** Спросите у друга:

— готовил ли он сегодня домашнее задание;
— выйдет ли он вечером с вами на улицу;
— нравится ли ему спорт;
— на какой кружок он ходит.

**7.** Бирелгән план буенча «Минем дусларым бар» дигән темага хикәя төзеп карагыз.

1. Без кайда таныштык? (Авылда, шәһәрдә, экскурсиядә, мәктәптә, лагерьда, кинода, урамда.)

2. Без кайчан дуслаштык? (Җәй көне, кышкы каникулда, мәктәпкә барганда, тәнәфестә, урамда уйнаганда.)

3. Без бергә нишлибез? (Бергә уйныйбыз, дәрес әзерлибез, мәктәпкә йөрибез.)

4. Ул нинди? (Ярдәмчел, игътибарлы, шаян, гадел, көчле.)

# 44 нче дәрес

1. **Исегездә калдырыгыз!**

**Сыйфатлар** (имена прилагательные) **нинди?** соравына җавап бирәләр (отвечают на вопросы *какой? какая? какое? какие?*).

**Сыйфат дәрәҗәләре**
**Степени сравнения прилагательных**

Гади (положительная) дәрәҗә — **зәңгәр, кара.**

Чагыштыру (сравнительная) дәрәҗәсе — **зәңгәррәк, карарак.**

Артыклык (превосходная) дәрәҗәсе — **зәп-зәңгәр, кап-кара.**

Кимлек (уменьшительная) дәрәҗәсе — **зәңгәрсу, аксыл.**

2. Рәсемгә карагыз һәм сорауларга җавап бирегез.

1. Кайсы алма иң зур алма?
2. Иң кечкенә алма кайсы?
3. Кайсы алмалар зуррак?



3. Бирелгән сыйфатларга антонимнар табыгыз.

ак — ...　　　　әдәпле — ...
салкын — ...　　йомшак — ...

4. Бу төсләрнең кайсылары сезгә ошый? Сыйфатларның дәрәҗәләрен билгеләгез.

Зәңгәр, зәп-зәңгәр, алсу, кып-кызыл, кызылрак, сары, сап-сары, яшел, ямь-яшел, ак, аксыл, ап-ак, кара, кап-кара.

5. Табышмакның җавабын табыгыз.



Тоз түгел — ак,
Боз түгел — каты,
Кар түгел — эри.

**6.** Дустыгызның тышкы кыяфәте турында сөйләгез. Аңа мактау сүзләрен әйтегез.

Күзе: зәңгәр, соры, кара.



Чәче: озын, кыска, сары, кара, бөдрә.



Күлмәге: матур, яңа, чиста.



**7.** «Ул кем?» уенын өйрәнегез. Иптәшләрегез белән уйнагыз. Уен түбәндәгечә уйнала: сез бер сыйныфташыгызның тышкы кыяфәте турында сөйлисез, кигән киемен әйтәсез. Ә иптәшләрегез сезнең кем турында сөйләгәнегезне белергә тиеш.

**8.** Как скажете о том, что:

— у вас есть друг;
— он отзывчивый, добрый;
— вы с ним вместе играете, готовите уроки, ходите в школу?

## 45–46 нчы дәресләр

**1.** Сүзләрне дөрес укыгыз, тәрҗемә итегез.

Тормадым [то́рмадЫ́м], барырга [ба°рЫ́рға́], юындым [йуЫ́ндЫ́м], алып чык [а°лЫ́п чық], кычкырды [қЫ́чқЫ́рдЫ́].

**2.** Ике баганада бирелгән сүзләрдән сүзтезмәләр төзеп языгыз.

| | | |
|---|---|---|
| чәй | ? | барырга |
| урамга | | әзерләргә |
| иртән | | чыгарга |
| дәрес | | юынырга |
| мәктәпкә | | эчәргә |

**3.** Бирелгән фигыльләрне үзгәртеп, таблицага урнаштырыгыз, җөмләләр төзеп языгыз.

| Хәзерге заман хикәя фигыль | | Үткән заман хикәя фигыль | | Боерык фигыль | |
|---|---|---|---|---|---|
| барлык | юклык | барлык | юклык | барлык | юклык |
| ... | ... | ... | ... | ... | ... |

Ф и г ы л ь л ә р: тора, бара, әзерлә, юына, эчә, чыга, керә, бозыла.

**4. Исегезгә төшерегез!**

**алып бар** — неси
**алып кайт** — принеси
**алып кер** — занеси
**алып чык** — вынеси

**алып бара** — несёт
**алып кайта** — приносит
**алып керә** — заносит
**алып чыга** — выносит

**5.** Как попросите друга:

— принести в школу лыжи;
— принести с огорода домой лопату;
— занести домой портфель;
— вынести на улицу мяч?

**6.** Хикәяне укыгыз. Малайлар нинди дуслар?

## Дусларга нигә күңелсез?

Мин бүген бик иртә тормадым. Бүген каникул бит. Мәктәпкә барырга, дәрес әзерләргә кирәкми. Шулай да торып юындым, чәй эчтем, аннан урамга чыктым. Ринат инде күптән урамда йөри икән.

— Гали, көрәк алып чык әле, — дип кычкырды ул.

— Безнең көрәк дачада шул, — дидем мин аңа.

— Алайса кәшәкәңне алып чык.

— Кәшәкәне суга тыгарга ярамый, ул бозыла, — дидем мин.

— Бар, алайса өеңә кереп кит! — диде ул, үпкәләп.

Мин өйгә кердем. Әти-әниләр эштә, өйдә мин ялгыз. Нигәдер күңелсез булып китте. Нигә икән?



**кәшәкә** — клюшка
**үпкәләп** — обидевшись
**ялгыз** — здесь: один
**күңелсез булып китте** — стало грустно
**суга тыгарга ярамый** — здесь: нельзя мочить

**7.** Текстны план буенча өч өлешкә бүлегез.

1. Галинең иртәнге режимы.
2. Гали урамда.
3. Галигә өйдә күңелсез.

**8.** Галинең иртәнге режимын күрсәткән җөмләләрне дәфтәрегезгә языгыз, фигыльләрнең заманын билгеләгез.

**9.** Бу җөмләләрнең кайсылары боеруны (повеление), кайсылары киңәшне (совет) белдерә?

1. Дәрес әзерлә. 2. Мәктәпкә барырга кирәк. 3. Урыныңны җыештыр. 4. Дәрес әзерләргә кирәк. 5. Мәктәпкә бар. 6. Көрәк алып чык. 7. Урыныңны җыештырырга кирәк.

**10.** Текстны сәнгатьле укырга өйрәнегез. 55 нче биттәге таблицага нигезләнеп, дөрес укуга бәя бирегез.

## 47 нче дәрес

**1.** Бу җөмләләрнең кайсылары боеруны (повеление), кайсылары үтенечне (просьба) белдерә? Дәфтәрегезгә языгыз.

1. Зинһар, ярдәм ит әле! 2. Миңа булыш әле. 3. Көрәк алып чык! 4. Көрәк алып чык әле. 5. Кибеткә бар! 6. Кибеткә бар әле. 7. Кәшәкәңне алып чык! 8. Бар өеңә кереп кит!

**2.** Рәсемнәр урынына — предмет исемнәрен, нокталар урынына үтенечне белдергән сүзләрне языгыз.

1. Айрат, урамга  алып чык … .

2. Диләрә, мин  алыйм … .

3. Миңа  бир … .

**3.** Попросите родителей купить вам:

  

**4.** Диалогларны хикәя эчтәлеге тәртибендә (в последовательности содержания рассказа) урнаштырыгыз, үзара сөйләшегез.

1. — Алайса кәшәкә алып чык!
— Кәшәкә бозыла.
— Бар, өеңә кереп кит!

2. — Гали, көрәк алып чык әле!
— Безнең көрәк дачада шул.

**5.** Попросите друга показать на карте

города: Елабугу, Казань, Зеленодольск, Заинск;
реки: Волгу, Каму, Ик, Вятку, Свиягу.




**6.** Вежливо попросите друга:

— выйти на улицу поиграть;
— вынести на улицу футбольный мяч;
— помочь сделать домашнее задание.

**7.** Какой разговор состоится между мальчиками в рассказе «Дусларга нигә күңелсез?», если Ринат выразит просьбу в вежливой форме? Составьте диалог.

**8.** Бирелгән схемалар буенча диалоглар төзегез.

1) приглашение — благодарность;
2) приглашение — отказ с выражением благодарности.

**9.** Попросите родителей купить вам:

  

# 48 нче дәрес

**1.** Җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз.

1. Ринат инде күптән урамда йөри икән. 2. Мин өйгә кердем. 3. Нигәдер күңелсез булды. 4. Мәктәпкә барырга, дәрес әзерләргә кирәкми. 5. Мин бүген бик иртә тормадым. 6. Мин дә урамга чыктым. 7. Ринат миңа: «Көрәк алып чык әле!» — дип кычкырды. 8. Мин көрәк алып чыкмадым. 9. Ринат миңа: «Өйгә кереп кит», — диде.

**2.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Ни өчен Галигә дәрес әзерләргә һәм мәктәпкә барырга кирәкми?
2. Ул урамда кемне күрде?
3. Ринат Галидән нәрсә сорады?
4. Ул ничек сорады?
5. Гали нәрсә дип җавап бирде?
6. Галигә нигә күңелсез булды?
7. Ринат нигә үпкәләде?

**3.** Ни өчен малайларга күңелсез? Фикерегезне языгыз.

1. Галигә күңелсез, чөнки ... .
2. Ринатка күңелсез, чөнки ... .

**4.** Подумайте и скажите, как должен был обратиться Ринат к Гали, чтобы поддержать вежливый тон разговора.

**5.** Как вы думаете, какой ответ мог бы дать Гали, чтобы прийти к взаимному согласию? Выберите один из ответов.

1. Безнең көрәк дачада шул. 2. Миңа әнием рөхсәт итми. 3. Безнең көрәк юк. 4. Әйдә күршедән сорыйбыз. 5. Әйдә Сашаны чакырабыз, аның көрәге бар.

**6.** Текстны план буенча сөйләгез.

1. Каникулның беренче көне.
2. Гали урамга чыкты.
3. Ринат Галидән көрәк сорады.
4. Ринат үпкәләде.
5. Галигә өйдә күңелсез.

**7.** Галигә дә күңелсез, Ринатка да күңелсез. Сез ничек уйлыйсыз, кем гаепле? Бу фикерләрнең кайсылары белән килешәсез?

1. Гали гаепле, чөнки ул көрәген бирмәде. 2. Ринат гаепле, чөнки ул әдәпле итеп (вежливо) сорамады. 3. Гали гаепле, чөнки ул өенә кереп китте. 4. Ринат та, Гали дә гаепле, чөнки алар матур сөйләшмәделәр.

**8.** Гали белән Ринат чын дуслар булсалар, хикәя ничек үзгәрер иде? Хикәя төзегез һәм аны сәхнәләштерегез.

**9.** Үзегез төзегән хикәяне сөйләргә өйрәнегез.



# БЕЗНЕҢ БӘЙРӘМНӘР

## 49–50 нче дәресләр

**1.** Текстны укыгыз. Аңа исем куегыз.

Тиздән иң күңелле бәйрәм — Яңа ел бәйрәме җитә. Без яңа елны өйдә әти-әниләр белән бергә каршылыйбыз. Нинди күңелле бу бәйрәм! Без әти белән ёлка бизибез, ә әнием тәмле-тәмле ризыклар, яңа ел бәлеше пешерә. Без апа белән аңа булышабыз. Кич белән сәгать унда табын янына утырабыз, тәмле ризыклар ашыйбыз, бер-беребезгә бүләкләр бирәбез.

**2.** Текстка план төзегез, эчтәлеген бер-берегезгә сөйләгез.

**3.** **Исегездә калдырыгыз!**

**быел** — в этом году
**иске ел** — старый год
**былтыр** — в прошлом году
**яңа ел** — новый год
**кичә** — вчера
**бүген** — сегодня



**4.** Шигырьне укыгыз. Шигырьдә сүз нинди көн турында бара?

### Яңа ел килгәч

Апа былтыр киткән иде,
Быел кайтты ёлкадан.
Ә мин былтыр яткан идем,
Быел тордым йокыдан.

Иске елны ертып ташлап,
Яңа елны башладык.
Былтыр пешкән бәлешләрне
Быел тагын ашадык.

Кичә мин биш яшьтә идем,
Бүген инде алтыда.
Яшем артты, акыл нишләр?
Артыр әле ансы да.

Б. Рәхмәт




**5.** Җөмләләрне укыгыз. Нокталар урынына тиешле сүзләрне куегыз.

1. Апа ёлкага ... китте, ... кайтты. 2. Мин ... йокларга яттым, ... тордым. 3. ... бәлеш пешердек, ... ашадык. 4. Мин ... биш яшьтә идем, ... миңа алты яшь.

**6.** Сорауларга җавап бирегез. Сораулар буенча үзара сөйләшегез.

1. Шигырьдә нинди көн турында сүз бара?
2. Бәлешне кайчан пешергәннәр?
3. Бәлешне кайчан ашаганнар?
4. Календарьның кайсы битен ертып ташлаганнар?

**7.** Сүзләрнең антоним парларын табыгыз.

| | | |
|---|---|---|
| быел — ... | иске ел — ... | рәхәт — ... |
| бүген — ... | яхшы — ... | зур — ... |

**8.** Сез Яңа ел бәйрәме турында бик күп шигырьләр, җырлар өйрәнәсез. Шул җырларны, шигырьләрне исегезгә төшерегез.

1. Чыршы, чыршы, без сине
Сагынып көттек ел буе,
Син тагын да матуррак
Бизәлгәнсең бу юлы.

С. Урайский

2. Тышта буран бөтен җиргә
Карлар тутыра.
Безнең бүлмәдә ямь-яшел
Чыршы утыра.

Җ. Тәрҗеманов

**9.** Диалогка төшеп калган җөмләләрне өстәгез. Иптәшегез белән сөйләшегез.

— Аня, мәктәптә чыршы бизәдегезме?
— … .
— Яңа ел бәйрәме кайчан башлана?
— Бәйрәм сәгать икедә башлана.
— … ?
— Бәйрәмгә ак күлмәк киям. Ә син нәрсә киясең?
— … .
— Мин шигырь сөйлим. Ә син?
— … .

## 51 нче дәрес

**1.** Рәсемнәргә карагыз һәм әйтегез: карнавалга кемнәр килгән? Алар баш киемнәрен дөрес кигәннәрме?



**2.** Текстны укыгыз һәм әйтегез: төрле илләрдә (в разных странах) Яңа елны ничек бәйрәм итәләр?



Вьетнамда Яңа елны каршылаганда нинди дә булса агач утырталар. Португалиядә сәгать төнге 12дә виноград ашыйлар. Бразилиядә борчак ашы пешерәләр. Грециядә, алтын-көмеш акча салып, торт пешерәләр. Акча кемгә эләгә, шул бәхетле була. Австралиядә Яңа елны җәй көне каршылыйлар. Балалар диңгез яры буенда комнан төрле сарайлар төзиләр.

**3.** Яңа ел белән котларга өйрәнегез.




— Алсу, сине Яңа ел белән котлыйм!

— Рәхмәт, Витя. Сине дә бәйрәм белән котлыйм! Сиңа сәламәтлек, укуыңда уңышлар телим.

**4.** Табышмакларның җавабын табыгыз.

1. Кышын таудан шуабыз,
   Җәен җыеп куябыз.

2. Канатсыз оча,
   Аяксыз чаба,
   Тышта өелә,
   Өйдә җәелә.

**5.** Кышкы уеннар турында диалог төзегез.



## 52–53 нче дәресләр

**1.** Текстны укыгыз. Бәйрәм белән котларга өйрәнегез.

### 8 нче Март — әниләр бәйрәме

8 нче Март — яз бәйрәме, әниләр бәйрәме, әбиләр бәйрәме, кызлар бәйрәме!

Бу көнне һәркем бүләк әзерли. Балалар — әниләргә, әбиләргә, апаларга, әтиләр — әниләргә, малайлар кызларга бүләк бирә.

Бүләк төрле була. Энә дә бүләк, дөя дә бүләк, диләр (говорят).

Мин әнигә булышам: гөлләргә су сибәм, савыт-саба юам. «Бу зур бүләк!» — ди әни. Әни белән табын әзерлибез — бу да зур бүләк. Котлау язу да бик зур бүләк. Мин әнигә менә нинди котлау яздым:



«Кадерле әнием!

Сине 8 нче Март бәйрәме белән котлыйм! Сиңа озын гомер, сәламәтлек, шатлык, зур уңышлар телим!

Улың Самат».

**бүләк** — подарок
**энә** — иголка
**булышу** — помощь
**дөя** — верблюд

**2.** Бу сүзләрне дөрес укыдыгызмы?

Озын [ŏзŏн], шатлык [шаᵒтлы́к], гомер [ғөмө́р], сәламәтлек [сәләмәтлә̆́к], уңышлар [уңы̆шла́р].

**3.** Кем кемгә бүләк бирә?

Малайлар — … .

Балалар — … .

Әтиләр — … .

Кызлар — … .

**4.** Рәсемгә карагыз һәм әйтегез: бу бүләкләрне кемгә бирәсез?









**5.** Рәсемнәр урынына сүзләр куегыз. Дустың белән үзара сөйләшегез.

— Син кемгә бүләк бирәсең?
— Әнигә, апага. Ә син?
— Мин дә әнигә, апага бүләк бирәм.
— Нәрсә бүләк итәсең?
— Әнигә , апага  .
— Ә син нәрсә бүләк итәсең?
— Мин дә әнигә , ә апага  .

**6.** Нокталар урынына җөмләләр куегыз. Дустың белән сөйләшегез.

— Айдар, син кая барасың?
— … .
— Ә нинди бәйрәм?
— … .

— Сез бәйрәмдә нишлисез?
— Әниләргә концерт куябыз. Ә син нишлисең?
— ... .

7. Нокталар урынына тиешле хәрефләрне, кушымчаларны куеп языгыз.

8 нче Март — б...йр...м к...н. Мин әни..., әби..., сеңлем... бүләк әзерләдем. Әни... ш...г...рь яздым. Укытучы апа... чәчәкләр бир... .

8. Укытучыгызга 8 нче Март бәйрәме белән котлау языгыз.

## 54–55 нче дәресләр

1. **Исегезгә төшерегез!**

| **Килешләр** Падежи | **Сораулар** Вопросы | **Аффикслар** Аффиксы | **Берлек сан** Единственное число |
|---|---|---|---|
| **Баш килеш** (Именительный падеж) | Кем? — Кто?<br>Нәрсә? — Что? | — | **әни** — мама<br>**бакча** — огород<br>**шәһәр** — город |
| **Иялек килеше** (Притяжательный падеж) | Кемнең? — Кого?<br>Нәрсәнең? — Чего? | -ның/-нең | **әнинең** — мамы<br>**бакчаның** — города<br>**шәһәрнең** — города |
| **Юнәлеш килеше** (Направительный падеж) | Кемгә? — Кому?<br>Нәрсәгә? — Чему?<br>Кая? — Куда? | -га/-гә<br>-ка/-кә | **әнигә** — маме<br>**бакчага** — в огород<br>**шәһәргә** — в город<br>**кибеткә** — в магазин<br>**урамга** — на улицу |
| **Төшем килеше** (Винительный падеж) | Кемне? — Кого?<br>Нәрсәне? — Что? | -ны/-не | **әнине** — маму<br>**бакчаны** — огород<br>**шәһәрне** — город |

| **Килешләр**<br>Падежи | **Сораулар**<br>Вопросы | **Аффикслар**<br>Аффиксы | **Берлек сан**<br>Единственное число |
|---|---|---|---|
| **Чыгыш килеше**<br>(Исходный падеж) | Кемнән? — От кого?<br>Нәрсәдән? — От чего?<br>Кайдан? — Откуда? | -нан/-нән<br>-дан/-дән<br>-тан/-тән | **әнидән** — от мамы (у мамы)<br>**урамнан** — с улицы<br>**киемнән** — с одежды<br>**бакчадан** — с огорода<br>**шәһәрдән** — из города<br>**парктан** — из парка<br>**кибеттән** — из магазина |
| **Урын-вакыт килеше**<br>(Местно-временной падеж) | Кемдә? — У кого?<br>Нәрсәдә? — У чего?<br>Кайда? — Где? | -да/-дә<br>-та/-тә | **әнидә** — на маме (у мамы)<br>**урамда** — на улице<br>**шәһәрдә** — в городе<br>**паркта** — в парке<br>**кибеттә** — в магазине |

**2.** Рәсемнәр урынына тиешле килештәге сүзләрне куеп языгыз.

Мин бу   бүләк итәм.

**3.** **Кибет**, **бәйрәм** сүзләрен килешләр белән төрләндерегез, җөмләләр төзегез.

**4.** Хикәяне укыгыз.

### Туган көн — иң күңелле бәйрәм

Тиздән Гүзәлнең туган көне. Аның дуслары бик күп. Ул әнисе белән сөйләшә.

— Кызым, туган көнгә кемнәрне чакырырга телисең?

— Әлфинурны, Сөмбелне, Оляны.

— Ә Ленаны чакырасыңмы?

— Әлбәттә, чакырам. Әнием, хәзер Ләйсәннәргә барам, ул да килә.

— Озак торма, кызым, миңа булышырга кирәк.

— Ярар, кибеткә дә керәм. Нәрсәләр алыйм?

— Алма, груша ал.

— Ярый, әнием, мин киттем.

**5.** Диалогларны «Туган көн» хикәясе эчтәлеге эзлеклелегендә (в последовательности) урнаштырыгыз.

1. — Туган көнгә нәрсәләр кирәк?
   — Алма, груша, конфетлар.
2. — Кызым, дусларыңны чакырырга телисеңме?
   — Әйе, дус кызларны чакырам.
3. — Әнием, кибеткә барыйммы?
   — Әйе, кызым, бар.

**6.** 4, 5 нче күнегүләрдәге диалогларны сәхнәләштерегез. Уйнаучыларга бәя бирегез.

**7.** Диалогны сөйләргә өйрәнегез.

— Гүзәл, син нәрсә аласың?

— Әни акмай, сөт алырга кушты.

— Ә яшелчә, җимешләр аласыңмы?

— Әйе, 1 кило алма, 1 кило груша, 1 кило помидор алам.

— Бик авыр була бит. Әйдә үзем булышыйм.
— Ярар, рәхмәт сиңа.

**8.** Рәсемнәргә карап, азык-төлек (продукты питания) исемнәрен татарча әйтегез.






**9.** 8 нче күнегү рәсемнәрендә күрсәтелгән ризыкларның кайсын ашыйбыз, кайсын эчәбез?

**10.** Спросите у продавца, сколько стоит: яблочный сок, чакчак, сахар, рыба.

## 56 нчы дәрес

**1.** Бу ризыкларның кайсылары татар халык ашлары? Исемнәрен искә төшерегез.



[бәлә́ш]



[өчпŏчма́қ]



[пыла́w]



[қы̆сты̆бы̆й]

   

[тŏқмачлы́   а°ш]   [чәкчә́к]   [қŏйма́қ]   [туңды́рма́]

**2.** Диалогларны рольләргә бүлеп укыгыз, үзара сөйләшеп карагыз.

1. — Әни, бүген нәрсә әзерлибез?
— Беренчегә — шулпа, икенчегә пылау әзерлибез.
— Чәй янына нәрсә куябыз?
— Гөбәдия.

2. — Оля, син салатлар яратасыңмы?
— Әлбәттә.
— Ә нинди салат яратасың?
— «Кышкы» салат.
— Ә миңа «Мимоза» салаты ошый.

3. — Люда, син гөбәдия пешерә беләсеңме?
— Юк. Гөбәдияне әнием пешерә.
— Аңа нәрсәләр сала?
— Дөге (рис), корт (кызыл эремчек — засушенный красный творог), йөзем, май, йомырка.

**3.** Кунаклар каршылаганда өстәлне ничек әзерлисез? Предметларның кайсын кая куясыз?



Б е л е ш м ә   ө ч е н   с ү з л ә р: уртага, уңга, сулга, өстенә, астына.

**4.** Шигырьне укыгыз.

## Кунаклар

Без әзерлибез табын,
Китереп бөтен ягын.
Уртага куйдык чәчәк,
Чәчәк янына — чәкчәк,
Бавырсак һәм кош теле.
Ризыклар төрле-төрле —
Сумса, бәлеш, өчпочмак,
Гөбәдия һәм коймак.
Һәркемгә чыгар өлеш,
Бар кыстыбый һәм бәлеш.
— Җитешегез, кунаклар!
Кыстатмагыз, кунаклар!
Өйгә кайтып китәргә
Ашыкмагыз, кунаклар!

Ш. Галиев



5. Иптәшегездән сорагыз: өстәлдә нинди ризыклар бар, нинди ризыклар юк?

6. Шигырьне ятлагыз.

## 57–58 нче дәресләр



1. Сез телефоннан сөйләшә беләсезме? Диалогларны укыгыз, иптәшегез белән сөйләшегез.

1. — Алло, Альбина апа, исәнмесез! Бу мин — Олег. Ә Марат өйдәме?
— Өйдә.
— Чакырыгыз әле.



2. — Алло, Сания апа, исәнмесез! Сезне Лена борчый. Миңа Алсу кирәк иде.
— Алсу өйдә юк әле.
— Ә кайда?
— Тренировкада.
— Кайчан кайта?
— Кичке сәгать 5тә.
— Ярый, рәхмәт. Мин тагын шалтыратам.

3. — Исәнме, Алсу! Бүген минем туган көнем. Сине туган көнгә чакырам.
— Сәгать ничәдә башлана?
— Сәгать кичке 4тә. Киләсеңме?
— Киләм. Рәхмәт.

2. 1 нче күнегүдәге диалогларга охшаш диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

3. Напишите, как позовёте своих друзей играть на улице.

4. Посоветуйте другу:

— долго не разговаривать по телефону;
— разговаривать по телефону вежливо.

5. Как скажете:

— телефон звонит, возьмите трубку;
— к телефону приглашают маму (папу);
— вы звонили подруге в школу?

6. Сезгә бу чакыруларның кайсы ошый? Дәфтәрегезгә языгыз.

**Лена!**

**Минем туган көнгә кил! Туган көн кич өйдә була.**

**Наташа!**

**Бүген минем туган көн! Туган көнгә кил!**

**Саша, минем туган көнгә кил. Бүләк алып кил! Онытма!**

**Гөлшат!**
**Сине бүген кичке сәгать алтыга туган көнгә чакырам. Рәхим ит!**

## 59–60 нчы дәресләр

1. Әйтик, сез дусларыгыз белән туган көнгә барасыз. Сезнең арада нинди сөйләшү булыр? Дәфтәрегезгә языгыз. Үзегез язган диалоглар буенча сөйләшеп карагыз.

Диалог өчен темалар:

1. Туган көнгә бару турында.
2. Очрашу урыны.
3. Бүләк алу.



**2.** Әйтик, сез туган көнгә килдегез. Дустыгызны туган көне белән котлагыз, комплиментлар әйтегез.

**3.** Рәсемгә карагыз һәм әйтегез: сез туган көндә нәрсәләр эшлисез?



**4.** Уенны өйрәнегез һәм иптәшләрегез белән уйнагыз.

## Ак калач

Уйнаучылар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Берсе уртага чыга. Җырның эчтәлеген хәрәкәтләр белән күрсәтәләр.

Булатның туган көненә
Без пешердек ак калач.
Менә шулай ул биек,
Менә шулай тәбәнәк.
Менә шулай киңлеге,
Менә шулай тарлыгы.
Ак калач, ак калач,
Теләгәнеңне алып кач.

**биек** — здесь: вышины
**тәбәнәк** — здесь: нижины
**киңлеге** — здесь: ширины
**тарлыгы** — здесь: ужины

**5.** Табышмакларның җавабын табыгыз. Аларны өйрәнегез, бер-берегезгә әйтегез.

1. «Алма», — дисәң дә алалар,
Нәрсә соң ул, балалар?





2. Сикерә бelә,
Йөгерә белми.




3. Ашамый, эчми,
Көне-төне йөри.

4. Үзе кып-кызыл,
Күлмәге ямь-яшел.





5. Үскәндә (когда растёт), яфрагын ашыйлар.
Үсеп җиткәч (когда вырастает), үзен ашыйлар.

**6.** «Без туган көндә» темасы буенча диалоглар төзегез.

## 61–63 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәсен сүзлектән табыгыз, дәфтәрегезгә языгыз. Алар сезгә хикәяне аңларга ярдәм итәр.

ризыклар — …
искиткеч — …
тәртиптә — …
уздырмыйбыз — …
иске — …
карт — …
сүзсез — …
бераз — …

**2.** Дәвам итегез.

Минем кунакларым
Синең …
Аның …
Безнең кунакларыбыз
Сезнең …
Аларның …

**3.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куеп языгыз.

1. Бүген Алсу… туган көн… . 2. Алсуның әни… тәмле-тәмле ризыклар пешер… . 3. Тиздән Алсуның кунаклар… килер. 4. Алсу кунаклар… каршы алырга әзерләнә.

**4.** Сүзләрнең антоним парларын табыгыз.

яңа — …
чиста — …
матур — …
карт — …
борчулы — …
дус — …

**5.** Хикәяне укыгыз. Фәридәнең туган көнен нигә уздырмадылар?

### Туган көндә

Бүген Фәридәнең туган көне. Әнисе иртән бик матур торт пешерде, өстәлгә тәмле ризыклар куйды.

Өйләре дә искиткеч матур бүген. Бөтен нәрсә чип-чиста, бар да тәртиптә. Бар да шундый матур, шундый күңелле! Тиздән аның дус кызлары да килеп җитәр.



Фəридə əнисе янына кухняга керде.

— Əни, əни, əйдə əби бүген генə залга минем кунакларым янына чыкмасын əле. Анда бөтен нəрсə матур, яңа, ə əби иске, шундый карт...

Əнисе башта аңламады. Аннан соң урындыкка утырды. Бераз сүзсез утырды ул. Аның күзлəре, йөзе бик борчулы иде...

— Менə нəрсə, Фəридə, дусларыңа шалтырат, бүген туган көнеңне уздырмыйбыз. Менə шулай, уздырмыйбыз... — диде ул.

Р. Вəлиева

**чыкмасын əле** — пусть не выходит
**аннан соң** — потом
**уздырмыйбыз** — не будем проводить
**бераз** — немного, некоторое время
**борчулы** — обеспокоенный; расстроенный
**иске, карт** — старый

Укы
һəм
тыңла

6. Бу сүзлəрне транскрипция билгелəре белəн языгыз, дөрес укыгыз.

Ризыклар, күңелле, кызлар, кунакларым, чыкмасын, карт, аңламады, урындыкка.

7. Җөмлəлəрне хикəя эчтəлеге тəртибендə урнаштырыгыз.

1. Фəридəлəрнең өйлəре искиткеч матур. 2. Бүген Фəридəнең туган көне. 3. Əнисе иртəн бик матур торт пешерде. 4. Менə Фəридə əнисе янына кухняга керде. 5. Бөтен нəрсə чип-чиста, бар да тəртиптə. 6. Бар да шундый матур, шундый күңелле!

**8.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны өстәп языгыз.

1. Фәридә... әнисе өстәл... тәмле ризык... куй... . 2. Фәридәләр... өйләр... чип-чиста. 3. Тиздән Фәридә... дус кызлар... килә... . 4. Фәридә, дусларың... шалтырат, бүген туган көнең... уздырмый... .

**9.** Җөмләләрне киңәйтеп языгыз.

Әнисе пешерде. Фәридә керде. Әби чыкмасын.

**10.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Фәридәнең әнисе нәрсәгә әзерләнә?
2. Фәридәнең әнисе нәрсә пешерде?
3. Фәридәнең әбисе кемнең әнисе?
4. Ни өчен Фәридәнең әнисе борчылды?
5. Фәридә үз хатасын аңлармы?

**11.** Фәридә үз хатасын аңлады, әнисе аны гафу итте, дип уйлыйк. Хикәя ничек дәвам итәр, язып карагыз. Үзегез язган хикәянең эчтәлеген сөйләргә өйрәнегез.

**12.** Представьте ситуацию:

1. У тебя больна бабушка. Спросите:
   — какая у неё температура;
   — что у неё болит;
   — надо ли ей лекарство, чай.

   Предложите выпить лекарство.

2. Вы с мамой накрываете на стол. Позовите бабушку к столу. Спросите:
   — как она будет пить чай: с молоком или без молока.

   Предложите ей чай с вареньем (с мёдом).
   Предложите ей фрукты.

## 64–65 нче дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**

**Янында** — около (өстәл янында — около стола); **янынннан** — от (өстәл янынннан — от стола); **янына** — к (өстәл янына — к столу); **өстендә** — на (өстәл өстендә — на столе); **өстенә** — на (өстәл өстенә — на стол); **өстеннән** — с (со) (өстәл өстеннән — со стола); **астында** — под (өстәл астында — под столом); **астыннан** — из-под (өстәл астыннан — из-под стола); **астына** — под (өстәл астына — под стол).

**2.** Нокталар урынына кушымчалар өстәп, күчереп языгыз.

1. Саша табын ян... утырды.
2. Саша табын ян... үзен әдәпсез тотты.
3. Саша табын ян... китте.

**3.** Тәрҗемә итегез.

Өстәл өсте чиста. Өстәл өстенә чәчәк куйдым. Өстәл өстеннән төш. Өстәл өстендә хат ята.

**4.** Калын хәрефләр белән бирелгән исемнәрнең килешләрен билгеләгез.

1. **Аштан итне** алды, **өстәлгә** куйды. 2. **Өстәлдән** алды, **урындыкка** куйды. 3. Әни **Сашага** аш бирде. 4. Саша иң зур **алманы** алды. 5. **Өстәлдә** тәмле **ризыклар** күп. 6. **Кунакта** күңелле. 7. **Хуҗага** рәхмәт әйттек.

**5.** Җөмләләрне укыгыз, тәрҗемә итегез.

1. Табын уртасында матур букет бар. 2. Ул тәрәзә алдында басып тора. 3. Шәһәр уртасында зур базар бар. 4. Күл янында камышлар үсә. 5. Мәктәп алдына чәчәкләр утырттык. 6. Ул парта өстеннән китапларны алды.

**6.** Текстагы сүзләрне дөрес укыгыз.

Табынга [та°бы́ңға́], савыт [са°wы́т], авызын [а°wы̆зы́н], малае [ма°лайы́], валчыклары [wа°лчы̆қлары́].

**7.** Хикәяне укыгыз. Сез Сашага охшар идегезме?

## Табын янында

Мин кичә бер гаиләгә кунакка бардым. Табын янына хуҗа малае Саша да утырды. Өстәл өстендә зур савыт белән салат тора. Саша салатны үз янына куйды һәм тиз-тиз ашый башлады. Хуҗабикә безгә аш бирде: башта миңа, аннан соң Сашага. Саша башкаларны көтмәде, ашны ашый да башлады. Ул авызын чапылдатып, сөйләшә-сөйләшә ашады. Кулы белән аштан итне алды һәм өстәлгә куйды. Десертка алма бирделәр. Хуҗа малае иң зур алманы сайлап алды да табын яныннан китте. Өстәл өсте бик пычрак калды: анда ит һәм ипи валчыклары аунап ята иде.



**аннан соң** — потом
**валчыклар** — крошки
**башкаларны** — остальных
**аунап ята иде** — валялись
**чапылдатып** — чавкая
**сөйләшә-сөйләшә** — разговаривая

**8.** Хикәяне абзацларга бүлегез һәм план төзегез.

**9.** Җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибендә (в последовательности содержания рассказа) күчереп языгыз.

1. Саша салатны үз янына куйды һәм тиз-тиз ашый башлады. 2. Өстәл өстендә зур савыт белән салат тора. 3. Табынга хуҗа малае Саша да утырды. 4. Десертка алма бирделәр. 5. Саша киткәннән соң, өстәл өсте бик пычрак

калды. 6. Хуҗа малае иң зур алманы сайлап алды да табын янынннан китте.

**10.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Саша салатны, ашны ничек ашады?
2. Ул итне ничек алды?
3. Саша нинди алманы сайлап алды?
4. Саша киткәч, өстәл өсте ничек калды?

**11.** Хикәягә сез бу исемнәрнең кайсын сайлар идегез?

1. Кунакта.
2. Хуҗа малае Саша.
3. Тәрбиясез Саша.
4. Саша өстәл янында.
5. Без табын янында.

Укы һәм тыңла

## 66 нчы дәрес

**1.** Уйлагыз: бу җөмләләр хикәянең эчтәлегенә туры киләме? Җөмләләрне хикәядәгечә үзгәртеп языгыз.

1. Мин бүген бер гаиләгә кунакка бардым. 2. Өстәл өстендә савыт белән салат тора. 3. Хуҗабикә башта Сашага, аннан соң миңа аш бирде. 4. Саша авызын чапылдатмый, матур итеп ашады. 5. Саша кулы белән аштан бәрәңге алды һәм өстәлгә куйды. 6. Саша иң кечкенә алманы алды.

**2.** «Табын янында» хикәясендәге җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз.

**3.** Әйтик, хикәядәге вакыйга кичә түгел, бүген бара. Хикәядәге фигыльләрне хәзерге заман формасына куеп сөйләп карагыз.

**4.** Сашаның табын янында үз-үзен тотышы сезгә ошадымы? Ул табын янында нинди кагыйдәләрне бозды?

**5.** Табын янында үз-үзеңне дөрес тоту буенча Сашага киңәшләр бирегез.

| Сашаның табын янында үз-үзен тотышы | Киңәшләр |
|---|---|
| Саша салатны үз янына куйды. | Саша, салатны үз янына куйма, уртага куй. |

**6.** Саша нинди малай? Аңа нинди бәя бирергә була?

Т е р ә к  с ү з л ә р: эшчән, акыллы, тәрбияле, тәрбиясез, әдәпле, әдәпсез, табын янында үз-үзен тота белми.

**7.** Әйтик, Саша — тәрбияле малай. Хикәя ничек үзгәрер? Дәфтәрегезгә языгыз. Үзегез язган хикәяне сөйләргә өйрәнегез.



# ТАТАРСТАН — ТУГАН ҖИРЕМ

## 67–68 нче дәресләр




**1.** Текстны укыгыз. Текст эчтәлегенә план төзегез.

Татарстан Республикасы Россия составына керә. Ул иң бай республикаларның берсе. Аның территориясе бик зур, 67 мең квадрат километрдан артык.

Татарстанның үз флагы, үз гербы, үз гимны бар. Татарстан флагында өч төс: яшел, ак, кызыл төсләр бар. Гербка ак барс рәсеме ясалган.

Татарстанда зур шәһәрләр бик күп: Казан, Яр Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Алабуга, Чистай, Зәй, Бөгелмә, Баулы һәм башкалар. Казан — безнең башкалабыз. Яр Чаллы — гигант машиналар шәһәре. Әлмәт — нефтьчеләр шәһәре. Алабуга — музейлар шәһәре. Түбән Кама — нефть химиясе шәһәре.

Татарстанда күптөрле милләт вәкилләре яши: татарлар, руслар, чувашлар, башкортлар, удмуртлар, марилар, мордвалар, азәрбайҗаннар, белоруслар, әрмәннәр, грузиннар һәм башка халыклар. Алар дус, тату яшиләр.

**2.** Җөмләләрне укыгыз. Бу раслаулар белән килешәсезме?

1. Татарстан — бай дәүләт. 2. Татарстан — зур дәүләт. 3. Татарстанның территориясе бик зур түгел. 4. Татарстан флагында өч төс: яшел, ак, зәңгәр төсләр бар. 5. Гербка ак барс рәсеме ясалган.

**3.** Диалогларга төшеп калган репликаларны куегыз, үзара сөйләшегез.

— Саша, Татарстанның символикасы нинди?
— ... .
— ... ?
— Ак барс рәсеме ясалган.
— Татарстанда нинди халыклар яшиләр?
— ... .
— ... ?
— Дус-тату яшиләр.

**4.** Как скажете о том, что:

— в Татарстане живут представители разных национальностей;
— они живут дружно;
— вы хорошо разговариваете по-русски, по-татарски и по-английски?

**5.** Шәһәр исемнәрен татарча әйтегез.

Казань, Мензелинск, Зеленодольск, Заинск, Чистополь, Нижнекамск, Альметьевск, Елабуга, Набережные Челны.

**6.** 5 нче күнегүдәге шәһәр исемнәре белән җөмләләр төзегез.

Ү р н ә к : Мин Казанга барам. Мин Казанда яшим. Мин Казаннан кайтам.

**7.** Нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз.

Мин Казан шәһ...р...ндә ...шим. Ә дустым Азат Әлм...т шәһәр...ндә ...ши. Аның әтисе — нефтьч... . Азат җәй к...н... Казанга килә. Мин аны к...тәм.

8. Диалогларны укыгыз. Иптәшегез белән сөйләшегез.

1. — Азат, син җәй көне кая барасың?
— Казанга.
— Кем белән?
— Әни белән. Ә син кая барасың?
— Чистайга.
— Чистайда кемнәр яши?
— Чистайда минем әбием, бабам яшиләр.

2. — Петя, Алабуга зур шәһәрме?
— Әйе, зур шәһәр. Алабугада университет бар.
— Алабуга Казаннан еракмы?
— Ерак.

## 69–71 нче дәресләр



1. Текстны укыгыз, җөмләләргә сораулар куегыз.

Казан — Татарстанның башкаласы. Ул бик зур, бик матур шәһәр. Казанда метро бар. Казанда театрлар, музейлар, спорт

корылмалары, ял парклары бик күп, цирк, зоопарк, зур китапханәләр бар.

Казанда спорт ярышлары бик еш (часто) уза. Казанга төрле илләрдән спортчылар килә. Алар Казанны бик яраталар, сокланалар (восхищаются).

Без сыйныф белән Казанга экскурсиягә бардык. Без Казан Кремлендә булдык. Безгә бигрәк тә (особенно) Сөембикә манарасы, Благовещение соборы ошады.

Кремль янында Дәүләт музее бар. Анда бик күп экспонатлар саклана. Безгә аеруча татар халкының киемнәре, бизәнү әйберләре бик ошады.

**2.** Тәрҗемәне истә калдырыгыз:

Казанский Кремль — Казан Кремле
Башня Сююмбике — Сөембикә манарасы
Мечеть Кул Шариф — Кол Шәриф мәчете
Благовещенский собор — Благовещение соборы









**3.** План пунктларын текст эчтәлеге тәртибендә (по последовательности содержания текста) урнаштырыгыз.

1. Татарстанның Дәүләт музее.
2. Казанда спорт ярышлары.
3. Казан Кремлендә.

**4.** Җөмләләрне тәгалләгез.

1. Казан бик ... . 2. Казанда театрлар, ... . 3. Без Казанга ... . 4. Музейда ... .

**5.** Текст эчтәлеген иң матур сөйләүчегә конкурс. Сөйләүчегә бәя бирергә онытмагыз.

**6.** Диалогларга төшеп калган репликаларны куегыз, үзара сөйләшегез.

— Россиянең башкаласы нинди шәһәр?
— ... .
— ... ?
— Татарстанның башкаласы — Казан шәһәре.

**7.** Как скажете, что вы:

— едете в Казань;
— живёте в Казани;
— приехали из Казани?

**8.** Выполните следующие ситуативные упражнения.

1. Уточните у друга, живёт ли он в Казани.
2. Как ответит друг, если он не живёт в Казани?
3. Предложите другу поехать в Казань.

Казан турында күбрәк бел

**9.** Дустыгыз белән сөйләшегез.

— Син кайсы урамда яшисең (торасың)?
— Мин Бауман урамында яшим.
— Син ничәнче йортта яшисең?
— 10 нчы йортта яшим.
— Ничәнче катта, ничәнче фатирда торасың?
— 3 нче катта, 12 нче фатирда яшим.

**10.** Продолжите рассказ о достопримечательностях Казанского Кремля.

Мин Казан Кремлендә булдым. Анда ... .



# ТУГАН ЯК ТАБИГАТЕ

## 72–74 нче дәресләр

**1.** Сүзләрне тәрҗемә итегез.

**Иксез-чиксез, тәбәнәк, бөрлегән, җәнлек, үзенчә, ел фасылы, шомырт, миләш.**

**2.** Сүзләрнең парларын табыгыз.

| | ? | |
|---|---|---|
| калын | | агач |
| тигез | | кыш |
| иксез-чиксез | | җәнлекләр |
| тәбәнәк | | елга |
| тәмле | | җәй |
| биек | | урманнар |
| усал | | кырлар |
| озын | | таулар |
| түгәрәк | | далалар |
| салкын | | күл |
| эссе | | җиләк |

**3.** Текстны укыгыз. Текст эчтәлеге буенча сораулар төзегез.

Татарстанның табигате төрле: калын урманнар да, елга-күлләр дә, тигез далалар да, иксез-чиксез кырлар, болыннар да, тәбәнәк кенә таулар да бар монда.

Урманнарда имән, чыршы, нарат, каен, юкә, шомырт, миләш агачлары, төрле дару үләннәре үсә. Ә нинди генә тәмле җиләкләр үсми анда! Кура җиләге, җир җиләге, бөрлегән, шомырт... Урманнарда поши, кабан, бурсык, төлке, куян, тиен, бүре кебек төрле җәнлекләр яши.

Идел, Чулман, Нократ, Агыйдел, Ык — Татарстан территориясендә иң зур елгалар.

Татарстанның климаты төрле. Безнең республикада дүрт ел фасылы да үзенчә матур: кыш — салкын һәм карлы;

яз — кояшлы һәм чәчәкле; җәй — эссе; көз — төрле төсләргә бай вакыт.

**4.** Сез бу раслаулар белән килешәсезме?

— Татарстанда биек таулар юк.
— Татарстанда урманнар да, далалар да бар.
— Бездә җиләкләр үсми.
— Урманнарда имән, чыршы, юкә, усак агачлары үсми.
— Татарстанда дүрт ел фасылы да бик матур.

**5.** Дәвам итегез.

1. Елгалар: Ык, ...
2. Агачлар: каен, ...
3. Җәнлекләр: поши, ...

**6.** План пунктларын текст эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз.

1. Татарстанның елга-күлләре.
2. Татарстанның климаты.
3. Татарстанның табигате төрле.
4. Татарстанның урманнары.

**7.** Кем тизрәк җавап бирә? Сөйләшүне үрнәк буенча дәвам итегез.

Үрнәк:
— Ык елгамы?
— Әйе, Ык — елга.
— Каен елгамы?
— Юк, каен елга түгел, каен — агач.
— ... ?

**8.** Рәсемнәр урынына сүзләр куеп, җөмләләрне языгыз.

1. Мин  белән  бардым. 2.  тәмле  үсә. 3. Без   җыйдык. 4.  янында түгәрәк  бар. 5. Күлдә без  тоттык.

**9.** 3 нче күнегү эчтәлеге буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

**10.** Предложите другу:

— пойти в лес (на речку);
— вместе собирать малину;
— купаться на речке;
— ловить рыбу.

**11.** Узнайте у друга:

— чем богат Татарстан;
— какие деревья растут в лесу;
— собирает ли он малину, землянику;
— какие звери обитают в лесах Татарстана;
— много ли озёр и рек;
— какие большие реки он знает;
— какие времена года ему нравятся.

**12.** 6 нчы күнегү планы буенча текстның эчтәлеген сөйләгез.

## 75–76 нчы дәресләр

**1.** Татарстанда яшәүче кыргый хайваннарның исемнәрен искә төшерегез.

| | | |
|---|---|---|
| аю | ? | лиса |
| төлке | | волк |
| бүре | | заяц |
| куян | | медведь |
| поши | | барсук |
| кабан дуңгызы | | лось |
| тиен | | кабан |
| бурсык | | белка |

Укы һәм тыңла

**2.** Диалогларны укыгыз, үзара сөйләшегез.

1. — Илназ, син хайваннар турында сөйләшергә яратасыңмы?

— Бик яратам. Миңа аеруча кыргый хайваннар дөньясы ошый.

— Син аларны каян беләсең?

— Журналлар укыйм, телевизор карыйм.

— Телевизордан нинди программа карыйсың?

— «Минем планетам» дип атала ул.

2. — Костя, әйдә иртәгә зоопаркка барабыз.

— Мин зоопаркта булдым инде.

— Анда яңа хайваннар, кошлар бар. Хәтта ак аюларны да китергәннәр.

— Мин ак аюлар турында укырга яратам, әйдә барабыз.

**3.** Әйтик, сезнең мәктәбегездә тиздән «Хайваннар дөньясы» дигән кичә булачак. Үзегезгә ошаган хайван турында чыгыш әзерләгез.

**4.** Табышмакларның җавабын табыгыз.

1. Песидән дә кечерәк ул.
Койрыгын күрсәң менә!
Күз ачып йомганчы,
Агач башына менә.





2. Хәйләкәр, ди, бик үзе,
Елтырый ике күзе.
Өч тавыкны салып китә
Җилкәсенә берүзе.

**5.** Ничек уйлыйсыз, малайлар табигать белән дусмы? Диалогларны үзара сөйләшегез.

1. — Мин урманда төлке күрдем.

— Курыктыңмы?

— Юк, курыкмадым, чөнки ул кешегә тими. Үзе курыкты.

2. — Кәрим, кара әле агач башына. Нәрсә күрәсең?

— Тиен! Нинди матур тиен!

— Әйе, ул чикләвек ашый.

— Ә нигә җиргә ыргыта (бросает)?
— Ул аларны кышка җыя.

3. — Коля, сезнең урманда нинди җәнлекләр бар?
— Куян, төлке, тиен.
— Ә аю бармы?
— Юк, безнең урман кечкенә.

4. — Коля, синең аю күргәнең бармы?
— Юк. Ә синең?
— Бар, әлбәттә.
— Чынлапмы? Кайда?
— Әлбәттә, зоопаркта.

**6.** Сүзлекләр ярдәмендә сүзләрнең тәрҗемәсен табыгыз.

а) Нарат, каен, имән, чыршы, юкә, усак, миләш.

ә) Карга, күгәрчен, торна, песнәк, акчарлак, чыпчык, сандугач, аккош, күке, тукран.

**7.** Сүзлек-чайнвордны чишегез.




1. Скворец.
2. Ласточка.
3. Воробей.
4. Ворона.
5. Лебедь.
6. Иволга.



8. Диалогларга төшеп калган репликаларны куегыз, үзара сөйләшегез.

— ... ?
— Татарстанның табигате бик бай.
— Татарстанда нинди агачлар үсә?
— ... .
— Татарстанда нинди җәнлекләр яши?
— ... .
— Татарстанда нинди кошлар яши?
— ... .

## 77–78 нче дәресләр

1. Текстны укыгыз. Ә сезнең керпе күргәнегез бармы?

Безнең урманнарда, бакчаларда керпе еш очрый. Зур керпенең 16 меңгә якын энәсе була. Энәнең озынлыгы 2–4 сантиметр, юанлыгы 1 миллиметр. Керпенең авырлыгы 1 килограммга, буе 30 сантиметрга җитәргә мөмкин.



Көз көне керпе тыныч урынга коры яфрак, үлән ташый. Ул кыш буе йоклый. Керпе бөҗәкләр, тычкан, гөмбә, җиләк, үлән ашый.

**2.** Дөрес укыдыгызмы?

[кә̆рпә́], [ӧ̆зӧ̆нлы́к], [йуанлы̆ғы́], [а°wы̆рлы̆ғы́], [ты̆ны́ч], [йа°фра́ҡ].

**3.** Тексттан табыгыз һәм укыгыз:

— керпенең энәләре турында;
— керпенең тукалануы турында.

**4.** Текстны файдаланып, керпе турында языгыз.

Керпенең энәләре саны ... .
Энәләрнең озынлыгы ... .
Керпенең буе ... .
Керпенең авырлыгы ... .
Керпе ... ашый.
Керпе кыш көне ... .

**5.** Иптәшләрегезгә керпе турында нинди сораулар бирә аласыз?

**6.** Диалогны өйрәнегез, үзара сөйләшегез.

— Оля, тыңла әле, яңалык әйтәм.
— Нәрсә булды?
— Мин кичә бакчада керпе күрдем.
— Тоттыңмы соң?
— Әйе, өйгә алып кердем.
— Ничек тоттың? Ул бит энәле.
— Сөлге белән тоттым. Өйдә сөт бирдем, ләкин ул эчми. Диван астында утыра да утыра.
— Наташа, син аны җибәр. Аның балалары бардыр. Ул сезнең бакчага алар өчен азык эзләп килгән, бакчада тычканнар күп.
— Ярар, Оля, син дөрес әйтәсең, рәхмәт сиңа.

**7.** Как скажете о том, что:

— вы увидели ёжика;
— он ещё маленький;
— ёжик испугался;
— вы принесли его домой?

# 79–80 нче дәресләр

**1.** Бөек шагыйрь Габдулла Тукай турында сөйләргә өйрәнегез.



Габдулла Тукай — бөек шагыйрь. 26 нчы апрель — шагыйрьнең туган көне. Ул көнне Казанда шигырь бәйрәме була.

Шагыйрьнең тормышы бик авыр була. Габдулла әтисез һәм әнисез үсә. Ул 27 ел гына яшәгән, ләкин бик күп шигырьләр, әкиятләр язган. Аның әсәрләрен (произведения) өлкәннәр дә, кечкенәләр дә бик яраталар.

**2.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Габдулла Тукай кем ул?
2. Ул нинди әсәрләр язган?
3. Ул ничә ел яшәгән?
4. Шагыйрьнең туган көне кайчан?

**3.** Мәсәлне укыгыз. Куян нигә үкенде?

### Ташбака белән Куян



Ташбака белән Куян ярышырга теләгәннәр. Алар бер таугa таба йөгерә башлаганнар. Куян, мин тиз йөгерәм, дип уйлый. Ул юлда йоклый.

Куян бервакыт уяна. Күрә: Ташбака тауга барып җиткән. Куян үкенде дә, хурланды да, әмма ни файда?!

Г. Тукайдан



**үкенде** — раскаялся
**дип уйлый** — думает, что …
**хурланды** — постыдился
**тауга таба** — в сторону горы

**4.** Дөрес тәрҗемәне табыгыз.

Йоклый —
а) заснул; ә) спит; б) спят.

Бервакыт —
а) вчера; ә) однажды; б) иногда.

Уяна —
а) проснулся; ә) просыпается; б) проснулись.

**5.** Ике раслауның кайсы дөрес?

1. Ташбака белән Куян бер елгага таба йөгерә башлаганнар.
   Ташбака белән Куян бер тауга таба йөгерә башлаганнар.
2. Ташбака, мин тиз йөгерәм, дип уйлый.
   Куян, мин тиз йөгерәм, дип уйлый.
3. Ташбака юлда йоклый.
   Куян юлда йоклый.
4. Куян тауга барып җиткән.
   Ташбака тауга барып җиткән.
5. Куян үкенде дә, хурланды да, әмма үкенүдән ни файда?!
   Ташбака үкенде, хурланды, ләкин үкенүдән ни файда?!

**6.** Мәсәлдәге җөмләләргә сораулар куегыз. Кем күбрәк сораулар уйлап таба?

**7.** Как скажете о том, что вы:

— участвуете в соревнованиях;
— на соревновании пришли первым;
— победили;
— не победили?

**8.** Бу мәкальне (пословицу) ничек аңлыйсыз?

Эш үткәч, үкенүдән файда юк.

**9.** «Ташбака белән Куян» мәсәленең эчтәлеген дустыгызга сөйләгез.

# 81–82 нче дәресләр



**1. Исегездә калдырыгыз!**

моя собака — этем / минем этем / минем эт

Эта собака моя. — Бу эт минеке.

2. Диалогка төшеп калган репликаларны өстәгез.

— ... ?
— Әйе, минем этем бар.
— ... ?
— Этем зур, матур.
— ... ?
— Юк, бу эт минеке түгел, Сашаныкы.
— ... ?
— Минеке кара.

3. Сүзләрне дөрес укыдыгызмы?

[қӧйрóқ], [йаᵒңá], [чаᵒбá], [бөтөрөлә́], [шаᵒтланá], [йаᵒлтӹрӹ́й].

4. Укыгыз, тәрҗемә итегез.

Койрык — ... .
Аның койрыгы — ... .
Койрыгын болгый — ... .

Күз — ... .
Аның күзләре — ... .
Күзләре ялтырый — ... .

**5.** Укыгыз һәм җавап бирегез. Этләр ничек шатлана?

— Койрыгын болгый (виляет хвостом).
— Күзләре ут яна (глаза горят).
— Шатланып өрә (радостно лает).
— Күзләре ялтырый (глаза сверкают).

**6.** Сезнең этегез ничек шатлана? Җөмләләрне язып бетерегез.

Аның күзләре ... , койрыгын ... . Ул минем янда ... .

**7.** Дөрес тәрҗемәне табыгыз.

| | |
|---|---|
| каршы ала | несёт |
| алып бара | встречает |
| тәпиен бирә | любит играть |
| уйнарга ярата | снимает варежки |
| бияләйне салдыра | подаёт лапу |

**8.** Спросите у друга:

— есть ли у него собака;
— подаёт ли она лапу;
— играет ли с ним.

**9.** Рәсемнәр эчтәлеге буенча диалоглар төзегез. Үзара сөйләшегез.



**10.** Этләрнең матур гадәтләре турында сөйләргә өйрәнегез. Ошаган гадәте турында рәсем ясап килегез.

## 83–84 нче дәресләр

**1.** Нокталар урынына төшеп калган кушымчаларны өстәп языгыз. Текстның эчтәлеген бер-берегезгә сөйләгез.

Минем эт... бар. Аның кушаматы (кличка) — Актүш. Актүш өй... яши. Ул бик матур, акыллы. Без Актүш... бик яратабыз. Ул без... белән уйный. Актүш... безнең белән рәхәт.

**2.** Бирелгән сүзтезмәләр белән җөмләләр төзегез.

Дүрт аяклы дустым. Күзләре ут яна. Шатланып өрә. Авылда яши. Тәпиен бирә. Бияләйне салдыра.

**3.** Укыгыз. Этләр нинди була? Тәрҗемә итегез.

| Эт кушаматлары | Акбай, Караборын, Актүш, Рекс, ... |
|---|---|
| Токымы (порода) | йорт эте (дворняжка), ау эте (охотничья), сакчы эт (сторожевая) |
| Кыяфәте | йонлач, озын колаклы, зур, кечкенә |
| Гадәте | исәнләшә, тәпиен бирә, командалар үти |
| Шатланганда | койрыгын болгый, күзләре ут яна, күзләре ялтырый |
| Эткә кайчан рәхәт? | хуҗасы булса, торыр урыны булса, ашарына булса, дуслары булса |
| Эт нинди була? | акыллы, усал, юаш, хуҗасына тугры |

4. Таблица эчтәлеге аша бер-берегез белән сорау-җавап формасында сөйләшегез.

5. Сорауларга җавап бирегез.

1. Сиңа нинди эт ошый? Аның кушаматы ничек?
2. Ул нинди токымнан?
3. Аның кыяфәте нинди?
4. Этнең нинди гадәтләре бар?
5. Ул усалмы? Акыллымы?

6. 5 нче күнегү сорауларына җавапларны язмача әзерләгез.

## 85 нче дәрес

1. Рәсемдәге этләрнең тышкы кыяфәтләре турында сөйләгез.



2. Диалогларны укыгыз. Сезгә кайсы эт күбрәк ошый? Ни өчен?

1. — Синең этең нинди токымнан?
— Овчарка.
— Аның кушаматы ничек?
— Джек. Ул бик акыллы. Зур гәүдәле, озын колаклы. Джек — сакчы эт. Ул командалар үти.
— Ә минем этем — болонка. Аның кушаматы — Леди. Ул йонлач, кечкенә генә, туп кебек!
— Ә нинди гадәтләре бар?
— Ул, ике тәпиенә басып, матур итеп бии белә. Леди матур этләр конкурсында катнашты. Аның медале бар.

2. — Минем этем бик акыллы.
— Ул нинди токымнан?

— Колли. Кушаматы — Чарли. Без аның белән бик дус. Ул озын йонлы. Мин нәрсә әйтсәм, шуны аңлый. Исәнләшә, тәпиен бирә.

**3.** 2 нче күнегүдән эт токымнары исемнәрен табыгыз. Аларның сыйфатларын языгыз.

Үрнәк: Минемчә, овчарка яхшырак, чөнки ул ... .

**4.** Әйтик, сезнең дустыгыз эт алырга тели. Сез нинди эт алырга киңәш бирер идегез? Киңәшегезне дәлилләгез.

**5.** Җөмләләрдән исемнәрне табыгыз, килешләрен билгеләгез. Текстның эчтәлеген сөйләгез.

Минем этем бар. Аның кушаматы — Акбай. Мин этемне бик яратам. Ул башка малайларны яратмый, мине генә ярата. Мин этемә ашарга бирәм, этемне уйнарга алып чыгам. Минем этем — ишегалдыбызда иң матур эт.

**6.** Үзегезгә ошаган эт токымы турында сөйләргә өйрәнегез.

**7.** Диалогка төшеп калган репликаларны өстәп языгыз, үзара сөйләшегез.

— Синең этең бармы?
— ... .
— Аның кушаматы ничек?
— ... .
— Этең кайда яши?
— ... .
— Этең синең белән ничек исәнләшә?
— ... .
— Ә ул саубуллаша беләме?
— ... .
— Ничек саубуллаша?
— ... .
— Аның нинди гадәтләре бар?
— ... .
— Син этеңне яратасыңмы?
— ... .

# БЕЗ СПОРТ ЯРАТАБЫЗ



## 86–88 нче дәресләр

**1.** Рәсемнәргә карагыз һәм әйтегез: балалар нишлиләр?











**2.** Сораулар конкурсы. Рәсемнәргә карата кем иң күп сорау төзи ала? Сорауларны дәфтәрегезгә языгыз, бер-берегез белән сөйләшегез.

**3.** Бирелгән сүзләрне ике баганага языгыз.

| Кыш көне | Җәй көне |
|---|---|
| ... | ... |

Хоккей, футбол, биатлон, фигуралы шуу, баскетбол, волейбол, теннис, чаңгы шуу, бадминтон.

**4.** а) Узнайте у друга:

— идёт ли он на стадион;
— любит ли он играть в футбол;
— играет ли он в волейбол.

б) Предложите ему:

— пойти на стадион;
— поиграть в футбол;
— вместе покататься на лыжах.

**5.** Төшеп калган репликаларны куеп, диалогларны язып бетерегез, үзара сөйләшегез.

— ... ?
— Әйе, мин йөзә беләм.
— Син яхшы йөгерәсеңме?
— ... .
— ... ?
— Саша яхшы йөгерми, ул тиз йөзә.

**6.** Вам хочется играть в волейбол. Позовите друга, скажите ему, что сегодня хорошая погода.

**7.** Вы катаетесь на роликовых коньках. А ваш друг почему-то не катается. Спросите, почему он не катается.

**8.** Посоветуйте другу заниматься спортом и посещать спортивный кружок.

**9.** Предложите своему другу пойти на стадион.

# 89–90 нчы дәресләр

**1.** Рәсемгә карап, тән әгъзаларының (части тела) исемнәрен әйтегез.



**2.** Әйтик, Саша янына табиб килде. Алар арасында нинди сөйләшү булыр? Төшеп калган репликаларны языгыз. Үзара сөйләшегез.

— Саша, кайсы җирең авырта?
— ... .
— Колагың авыртамы?
— ... .
— Аягың авыртамы?
— ... .
— Температураң бармы?
— ... .



**3.** Икенче баганадан туры килгән тәрҗемәне сайлап алыгыз.

| | | |
|---|---|---|
| башым авырта | ? | голова болит |
| миңа салкын тиде | | я простыл |
| минем температурам бар | | у меня кружится голова |
| башым әйләнә | | у меня есть температура |

4. Ситуатив күнегүләрне эшләгез.

1. Допустим, вы заболели. Как вы сообщите об этом матери?

2. Вам нужно принять лекарство. Как вы попросите у мамы лекарство?

3. Допустим, у вас заболел друг. Предложите ему лекарство.

4. Во время игры нечаянно упал ваш друг. Вы хотите узнать, что у него болит. Как вы спросите?

5. У друга болит рука. Как он об этом скажет?

5. Отгадайте кроссворд.

1) дыхание
2) сердце
3) кашель
4) горло
5) палец
6) кружок
7) врач
8) поясница
9) колено
10) нога




6. Бу кешеләрнең кайсы җире авырта? Аларга нинди табибка керергә кирәк?







Үрнәк: Коляның теше авырта. Аңа теш табибына керергә кирәк.

**7.** Нинди табибка әйтерсез?

Минем тешем сызлый.

Минем эчем авырта.

Минем бармагым сызлый.

Минем күзем начар күрә.

Терәк сүзләр: күз табибы, теш табибы, терапевт, хирург.

**8.** Бирелгән сүзләрне тәрҗемә итегез, җөмләләр төзеп, дәфтәрегезгә языгыз.

Арка, бил, йөрәк, керфек, үкчә, үпкә, тез, каш, күз, эч.

**9.** «Терапевтта» дигән темага диалог төзеп, үзара сөйләшегез.

## 91–92 нче дәресләр

**1.** Сорауларга җавап бирегез, үзара сөйләшегез.

1. Сез нинди спорт түгәрәгенә йөрисез?
2. Сез спорт түгәрәгендә нишлисез?
3. Сезнең дусларыгыз нинди спорт түгәрәгенә йөри?

**2.** Әлмәт шәһәреннән Булат Мотыйгуллин менә нинди шигырь язган.

### Сәламәт булыйк

Спортчы булмасам да,
Һәр көн һавада булам.
Йөгерәм, уйныйм һәм чабам,
Үземә көч-дәрт алам.



Саф һава керсә үпкәмә,
Шунда инде файда бар.
Нигә шуны аңламыйлар
Тәмәкече малайлар?

**көч-дәрт** — сила
**тәмәкече** — курильщики

3. Ничек уйлыйсыз, шигырь юлы аша Булат нинди киңәш бирә?

4. На соревнованиях ваш друг занял первое место. Какой комплимент вы ему скажете?

5. Табышмакларның җавабын табыгыз.

1. Кышын таудан шуабыз,
   Җәен җыеп куябыз.

2. Канатсыз оча,
   Аяксыз чаба,
   Тышта өелә,
   Өйдә җәелә.

6. Кышкы уеннар турында диалоглар төзегез. Үзара сөйләшегез.



# БЕЗ ЮЛДА

## 93–95 нче дәресләр

**1.** Шигырьне укыгыз. Автор балаларга нәрсә әйтергә тели?

**Әмир машиналары**

Урам тулы машина:
«Рено», «Пежо», «Иж Ода»...
Алар артыннан җилдерә
«Хундай», «Хонда», «Шкода»!

Алдан чаба «Вольво», «Ниссан»,
«Тойота» да «Шевроле»...
Тик «БМВ», «Феррари»га
Җитәлмиләр шул әле!



Менә чаттан килеп чыга
«Жигули» белән «УАЗ».
«Түт-түт», — диеп, сәлам бирә
Зур йөк төягән «КАМАЗ»...

Әмирнең бар әле тагын
Автобусы, краны...
Автопаркы тулып бара! —
Сөендерә шул аны...

Х. Әхмәт-Вәли

**2.** Текстны укыгыз. Сез бу эчтәлек белән килешәсезме? Тексттагы җөмләләргә сораулар куегыз. Үзара сөйләшегез.

Урамнарда машиналар бик күбәйде. Нинди генә машиналар юк хәзер. Шуның өстенә автобуслар, троллейбуслар, трамвайлар... Җәяүлеләр (пешеходы) өчен бик куркыныч. Балаларга аеруча сак булырга кирәк. Юл кагыйдәләрен һәрвакыт төгәл үтәргә кирәк.

**3.** Юл йөрү кагыйдәләрен искә төшерегез. Рәсемнәргә карагыз. Бу кагыйдәләр нинди рәсемнәргә туры килә?

1. Юл янында уйнарга ярамый.

2. Җәяүлеләр тротуардан гына йөрергә тиеш.

3. Юл аркылы бары тик рөхсәт ителгән җирдән генә чыгарга ярый.

4. Юл аша чыкканда, башта — сулга, аннан уңга кара.

5. Трамвай, троллейбус артына тотынып барырга ярамый.

6. Трамвай, троллейбус барганда, сикереп төшәргә ярамый.











4. Объясните братишке или сестрёнке, что:

— переходить улицу надо на зелёный свет светофора;
— нельзя выходить из трамвая и троллейбуса на ходу;
— нужно быть внимательным при переходе через дорогу;
— переходить через дорогу можно только в разрешённых местах.

5. Рәсем эчтәлеге буенча диалоглар төзегез.



Юл йөрү иминлеге порталы белән таныш

## 96–97 нче дәресләр

**1.** Тәрҗемә итегез, җөмләләр төзегез.

аша, аркылы — юл аша (аркылы)
буенча — урам буенча
ал — машина алдыннан
арт — трамвай артыннан

**2.** Тиешле бәйлекләрне куеп, җөмләләрне күчереп языгыз.

1. Юл ... чыкканда сак булыгыз!
2. Урам ... машиналар күп йөри.
3. Мәктәпкә барганда, юл ... чыгарга кирәк.

**3.** Кем хаклы һәм ни өчен? Диалогны ничек үзгәртер идегез?

— Сәлам, Миша! Әйдә безнең белән.
— Сәлам! Ә сез кая барасыз?
— Тукталышка барабыз, анда шундый күңелле.
— Нинди кызык уен таптыгыз?
— Трамвайның артына ябышасың (цепляешься) да рәхәтләнеп роликта шуып барасың.
— Куркыныч икән!
— Һи-и, бернәрсә дә булмый! Курыкма!

**4.** Җөмләләрнең башын һәм ахырын билгеләгез, эчтәлеген сөйләгез.

Юл буенда уйнарга ярамый транспорттан чыккач ашыгырга ярамый җәяүлеләр тротуардан гына йөрергә тиеш юл аркылы бары тик рөхсәт ителгән җирдән генә чыгарга ярый юл аша чыкканда, башта — сулга, аннан уңга кара юл аша чыкканда ашыкма.

**5.** Посоветуйте другу:

— не нарушать правила дорожного движения;
— не играть вблизи дороги;
— переходить улицу в положенном месте;

— ходить только по тротуару;
— переходить улицу на зелёный свет светофора.

**6.** Рөстәмгә ничек булышырсыз? Диалогны дәвам итегез, сөйләшергә өйрәнегез.

— Рөстәм, нишләп торасың монда?
— Мин циркка, абый янына бара идем.
— Бара беләсеңме соң?
— … .
— … .

## 98–99 нчы дәресләр

**1.** Рәсемнәрдәге юл йөрү билгеләрен аңлатып языгыз.



**2.** Тәрҗемә итегез:

через дорогу — …
по дороге — …
у светофора — …
пешеход — …

правила дорожного движения — …
перед трамваем — …
за машиной — …
подземный переход — …

Юл йөрү билгеләре турында күбрәк бел

**3.** Сез ничек уйлыйсыз, юлда светофор ни өчен кирәк?

**4.** Сез бу фикерләр белән килешәсезме?

— Машиналар булганда, юл буенда уйнарга ярамый.
— Юл аркылы чыкканда, башта уңга кара.
— Юлда машина булмаса, светофорга карау кирәк түгел.
— Җәяүле тротуардан гына йөрергә тиеш.
— Транспорт артынаябышырга ярамый.
— Светофор — җәяүленең дә, транспортның да дусты.

**5.** Җөмләләр төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| Игътибарлы<br>Тәртипсез<br>Игътибарсыз<br>Әдәпле, яхшы | кеше | юл йөрү кагыйдәләрен төгәл үти.<br>юл йөрү кагыйдәләрен төгәл үтәми. |

**6.** Тәрҗемә итегез.

1. Я живу недалеко, только через дорогу. 2. На повороте не видно машины. 3. Он не стал ждать, когда загорится зелёный свет светофора. 4. Ты должен знать правила дорожного движения.

**7.** Юл йөрү кагыйдәләрен сөйләгез.



# 100–102 нче дәресләр

**1.** Сез татар милли уеннарын беләсезме?



Татарча көрәш



Ат чабышы



Капчык киеп йөгерү



Бүрәнә өстендә капчык (мешок) белән сугышу



Чүлмәк вату (битьё горшка)



Баганага менү (лазание на столб)

**2.** Сүзләрне дөрес әйтергә өйрәнегез.

Көрәш [көрә́ш], чабыш [ча°бы́ш], капчык [қа°пчы́қ], бүрәнә [бүрәнә́], йөгереш [йөгөрө́ш], багана [ба°ғана́], чүлмәк [чүлмә́к], вату [wa°ту́].

**3.** Тәрҗемә итегез. Дәфтәрегезгә языгыз.

Азат белән Руслан көрәшә. Марсель атта чаба. Ленар белән Айрат бүрәнә өстендә капчык белән сугышалар. Тимур белән Саша капчык киеп йөгерәләр. Дамир баганага менә. Коля чүлмәк вата.

**4.** Фигыльләрне төрле заман формаларына куегыз.

| Хәзерге заман | Үткән заман | Киләчәк заман |
|---|---|---|
| көрәшә | ... | ... |
| атта чаба | ... | ... |
| йөгерә | ... | ... |
| сикерә | ... | ... |
| менә | ... | ... |
| вата | ... | ... |
| җырлый | ... | ... |
| бии | ... | ... |
| уйный | ... | ... |

**5.** Белдерүне укыгыз, тәрҗемә итегез.



**6.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Сабантуй кайчан була?
2. Сабантуй кайда була?
3. Сабантуй сәгать ничәдә башлана?
4. Программада нәрсәләр бар?

**7.** Диалогны рольләргә бүлеп укыгыз.

— Катя, син Сабантуйга барасыңмы?
— Әлбәттә.
— Әйдә бергә барабыз. Минем белән дус кызым Оля да бара.
— Син Сабантуйда нишлисең?
— Җырлыйм.
— Ә мин йөгерәм.

**8.** Дустыгызны Сабантуйга чакырыгыз. Сабантуйның кайчан, кайда буласын әйтегез.

Сабантуй турында мультфильмнар кара

# Сүзлек

## А

**аваз** — звук
**авыз** — рот
**авыл** — деревня
**авыр** — тяжело, тяжёлый; трудно, трудный
**авырта** — болит
**авырый** — болеет
**ага I** — течёт
**ага II** — дядя
**адым** — шаг
**аерылмас** — неразлучный
**азак** — конец, окончание
**азакны** — последний, конечный
**ай** — месяц, луна
**айлы** — лунный
**аккош** — лебедь
**акрын** — медленно; медленный
**акыллы** — умный
**ал I** — бери
**ал II** — перед
**ал III** — розовый
**алабуга** — окунь
**алай** — так
**алан** — поляна
**алайса** — если так, тогда
**аларныкы** — их
**алда** — впереди
**алдакчы** — обманщик
**алдаша** — обманывает, врёт
**алкышлар** — аплодисменты
**алмашлык** — местоимение
**алтау** — шестеро
**алтмыш** — шестьдесят
**алъяпкыч** — фартук
**анда** — там
**аннан** — затем
**аннан соң** — после
**аннары** — потом
**аны** — его, её
**аныкы** — его, её
**аның** — его, её
**анысы** — тот, та, то
**аң** — сознание, рассудок
**аңа** — ему, ей, к нему, к ней
**аңарда** — у него
**аңлашылды** — понятно
**ара** — промежуток, интервал, проход
**аралашу** — общение
**арзан** — дёшево; дешёвый
**арка** — спина
**аркылы** — через
**арт** — зад
**артка** — назад
**арткы** — задний
**артта** — позади, сзади
**арттырырга** — увеличить
**артык** — слишком, чересчур
**артына** — за
**арыдым** — устал(а)
**арыслан** — лев
**арыш** — рожь; ржаной
**ас** — низ
**аска** — вниз
**аскы** — нижний
**аста** — внизу, под
**ат чабышы** — скачки
**атаклы** — знаменитый
**атарга I** — бросать, кидать
**атарга II** — стрелять
**атларга** — шагать
**атна** — неделя
**ау эте** — охотничья собака
**аучы** — охотник
**ахры** — кажется, наверное
**ахыргы** — последний
**ахыры** — конец, предел
**ачу** — гнев

**ачуланып** — гневаясь, гневно
**ачы** — горький
**ачык** — открыто; открытый
**ашказаны** — желудок
**ашыга-ашыга** — торопясь; торопливо
**ашыгырга** — торопиться
**аяз** — ясно; ясный
**аяк** — нога

# Ә

**әгәр** — если
**әдәби** — литературный
**әдәп** — вежливость, приличие
**әдәпле** — вежливый, приличный
**әзер** — готовый
**әйбер** — вещь
**әйлән-бәйлән** — хоровод
**әкрен** — медленно
**әлбәттә** — конечно
**әле** — только, ещё
**әлифба** — алфавит, букварь
**әшәке** — плохой

# Б

**бабай** — дедушка, дед
**бавыр** — печень
**бавырсак** — баурсак (нац. кушанье)
**байлык** — богатство
**балан** — калина
**балачак** — детство
**балкырга** — сиять
**балыкчы** — рыбак
**барыбер** — всё равно
**барысы** — всего
**басу** — поле
**батарга** — тонуть
**батыр** — герой
**бау** — верёвка
**баш** — голова
**башка** — другой
**башкала** — столица
**башкаручы** — исполнитель
**башла** — начинай
**башларга** — начинать
**башта** — сначала, сперва
**бәби** — младенец
**бәйге** — состязание, конкурс, борьба
**бәйрәм** — праздник
**бәйрәмчә** — праздничный
**бәлеш** — бэлиш (нац. кушанье)
**бәлки** — авось, возможно, вероятно
**бәхет** — счастье
**бәхетле** — счастливый
**бәя** — цена
**белем** — знание
**белемле** — образованный
**бераз** — немного
**бервакыт** — однажды
**бергә** — вместе, совместно
**бердәм** — дружно; дружный
**бердәнбер** — единственный
**беркайда** — нигде
**беркайчан** — никогда
**беркая** — никуда
**беркем** — никто
**беркөн** — недавно, на днях
**бернәрсә** — ничего
**берни** — ничего
**берникадәр** — немного, несколько
**бернинди** — никакой
**берничә** — несколько
**берничек** — никак
**берсе** — один из них
**берсекөнгә** — послезавтра
**бертуктаусыз** — беспрерывно
**бетер** — кончай, заканчивай
**бетергеч** — ластик, резинка

**бетте** — кончено, кончился (-ась, -ось)
**биергә** — танцевать, плясать
**бизәк** — узор
**бизәлгән** — разукрашенный
**бик** — очень, весьма
**бикле** — запертый
**бил** — поясница
**билбау** — пояс, кушак
**билге** — отметка; знак; признак
**билгеле** — известный
**бина** — здание
**бирегә** — сюда
**биредә** — здесь
**биредән** — отсюда
**бирем** — задание
**бию** — пляска, танец
**биюче** — танцор
**бияләй** — варежки, рукавицы
**боз** — лёд
**бозарга** — портить
**болгатырга** — перемешивать
**болын** — луг; луговой
**болыт** — туча
**болытлы** — пасмурно; пасмурный
**борчак** — горох
**борчылу** — беспокойство
**борынгы** — древний
**борыч** — перец
**ботак** — ветка
**ботка** — каша
**бөек** — великий
**бөҗәк** — насекомое
**бөкләргә** — загибать
**бөтен** — целый
**буа** — пруд
**бугай** — кажется, как будто
**буена** — вдоль, по
**буйлап, буенча** — по
**бул** — будь
**булыш** — помогай
**буран** — метель, вьюга
**буш** — пустой
**бүл** — дели
**бүләк** — подарок
**бүлек** — глава
**бүлмә** — комната
**бүре** — волк
**бүрек** — шапка
**бүтән** — другой
**быел** — в этом году, ныне, нынче
**былтыр** — в минувшем году, в прошлом году

# В

**вак** — мелкий
**вакыт** — время, пора, период, срок, момент
**ват** — разбей, сломай, расколи
**Ватан** — Родина
**ватарга** — разбить
**ватык** — разбитый, сломанный
**ватылган** — разбитый
**вәгъдә** — обещание

# Г

**гадел** — справедливый
**гади** — простой
**гаеп** — вина
**гаепле** — виновный
**гаепсез** — невиновный
**гаҗәп** — удивительный
**газап** — мучение
**гаилә** — семья
**галим** — учёный
**гафу ит(егез)** — извини(те)
**гәүдә** — туловище, тело
**гомер** — жизнь
**горур** — гордый

**гөбәдия** — губадия (нац. кушанье)
**гөл** — цветок
**гөлбакча** — цветник
**гөлчәчәк** — роза
**гөмбә** — гриб
**гөрләвек** — ручеёк
**гүзәл** — прекрасный

## Д

**да, дә** — тоже; мин дә — я тоже
**давыл** — буря
**дару** — лекарство
**дәрес әзерли** — готовит уроки
**дәреслек** — учебник
**дәү** — большой
**дәүләт** — государство
**ди** — говорит
**димәк** — следовательно, таким образом
**диңгез** — море
**дистә** — десяток
**дөге** — рис
**дөнья** — мир, свет
**дуңгыз** — свинья
**дуңгыз ите** — свинина
**дус** — друг
**дускай** — дружок
**дуслык** — дружба
**дым** — влага

## Е

**егарга** — валить
**егет** — парень
**егыла** — падает
**егылырга** — падать
**ел** — год
**ел фасылы** — время года
**елан** — змея
**елга** — река
**елмаерга** — улыбаться
**елмая** — улыбается
**елый** — плачет
**ерак** — далеко
**ерακта** — вдалеке
**ерткыч** — хищник
**еш** — часто

## Ж

**җавап** — ответ
**җавап бир** — отвечай
**җавап бирә** — отвечает
**җанвар** — зверь
**җәен** — летом
**җәйге** — летний
**җәяү** — пешком
**җиләк** — ягода
**җимеш** — плод
**җиңел** — легко; лёгкий
**җиңү** — победа
**җитез** — ловко; ловкий
**җыенырга** — собраться
**җыр** — песня
**җырла** — пой

## З

**зарарлы** — вредно; вредный
**зат** — род, племя; лицо (I зат — I лицо)
**зәңгәр** — синий, голубой
**зур** — большой
**зыян** — вред

## И

**иген** — хлеб, хлеба
**игенче** — хлебороб
**игътибар** — внимание
**идән** — пол

**Идел** — Волга
**иҗат** — творчество
**иҗек** — слог
**икән** — оказывается
**икәү** — вдвоём
**икмәк** — хлеб
**ил** — страна
**илт** — отнеси
**илтергә** — отнести
**имеш** — будто бы, говорят, мол, якобы, дескать
**инә, энә** — иголка
**инеш** — ручей
**иң** — самый
**иптәш** — товарищ
**ир-ат** — мужчина
**ирек** — свобода, воля
**ирекле** — свободный
**ирен** — губа
**иркен** — просторный
**иртә** — утро
**иртәгә** — завтра
**иртән** — утром
**иртәнге** — утренний
**ис** — запах
**исә** — дует
**исән** — жив, здоров
**исәнләш** — поздоровайся
**исемлек** — список
**иске** — старый
**искиткеч** — изумительный
**ит** — мясо
**итле** — мясной
**ишек** — дверь
**ияк** — подбородок

## Й

**йодрык** — кулак
**йозак** — замок
**йокла** — спи
**йокы** — сон
**йола** — обряд
**йолдыз** — звезда
**йомшак** — мягкий
**йомшартырга** — смягчить
**йон** — шерсть
**йонлач** — мохнатый
**йорт** — дом
**йорт эте** — дворняжка
**йот** — глотай
**йөгер** — беги
**йөз I** — сто
**йөз II** — лицо
**йөз III** — плыви
**йөрәк** — сердце
**йөткерә** — кашляет

## К

**кабак** — тыква
**кабарга** — брать в рот
**кабатла** — повтори
**кагыйдә** — правило
**кадәр** — до
**кадерле** — дорогой
**каен** — берёза
**каз** — гусь
**казырга** — копать
**кайбер** — некоторый
**кайвакыт** — иногда
**кайгырта** — заботится
**кайда** — где
**кайнаган** — кипячёный
**кайнар** — горячий
**кайнарга** — кипеть
**кайсы** — который
**кайсыдыр** — кто-то
**кайчак** — иногда
**кал** — оставайся
**калын** — толстый
**камыр** — тесто
**кан** — кровь
**канат** — крыло

**капларга** — покрывать
**капчык** — мешок
**караңгы** — темно; тёмный
**карбыз** — арбуз
**карга** — ворона
**карлыган** — смородина
**карлыгач** — ласточка
**кармак** — удочка; крючок
**карт** — старый
**каршы** — противоположный
**каршыга** — навстречу
**каршылау** — встретить; встреча
**каршында** — перед
**кач** — прячься
**каш** — бровь
**кашык** — ложка
**кая** — куда
**каян** — откуда
**кәбестә** — капуста
**кәгазь** — бумага
**кәеф** — настроение
**кемдер** — кто-то
**кемнеке** — чей
**кер** — заходи
**керпе** — ёж
**керфек** — ресница
**кесә** — карман
**кеше** — человек
**ки** — надень
**кибет** — магазин
**кием** — одежда
**киен** — одевайся
**киләсе** — будущий
**кинәт** — вдруг
**киңәш** — совет
**киңәш итә** — советует
**кирәкле** — нужный
**кис** — режь
**кит** — уходи
**кич** — вечер
**кич белән, кичен** — вечером
**кичә I** — вчера
**кичә II** — вечер (напр., школьный)
**кичкә** — к вечеру
**кичке** — вечерний
**кишер** — морковь
**киштә** — полочка
**классташ** — одноклассник
**коен** — купайся
**коймак** — оладьи
**койрык** — хвост
**колак** — ухо
**колын** — жеребёнок
**коры** — сухой
**котлый** — поздравляет
**кош** — птица
**кояшлы** — солнечный
**көз** — осень
**көзен** — осенью
**көймә** — лодка
**көн** — день
**көндәлек** — дневник
**көндез** — днём
**көндезге** — дневной
**көнләшә** — ревнует, завидует
**көртлек** — тетерев
**көт** — жди
**көч** — сила
**көчле** — сильный
**куак** — куст
**куаклык** — кустарник
**куе** — густой
**кузгалак** — щавель
**куллан** — употребляй, используй, применяй
**кулъязма** — рукопись
**курка** — боится
**куркак** — трусливый
**кушамат** — кличка
**кушарга** — прибавить; присоединить
**күбәләк** — бабочка
**күз** — глаз

**күзлек** — очки
**күк I** — небо
**күк II** — синий
**күл** — озеро
**күлмәк** — платье, рубашка
**күнегү** — упражнение
**күңелле** — весело
**күпме** — сколько
**күрә** — видит
**күрше** — сосед
**күтәр** — поднимай
**күчә** — передвигается, перемещается; переезжает
**күчтәнәч** — гостинец
**кыйбат** — дорого
**кыңгырау** — звонок
**кыр** — поле
**кыргый** — дикий
**кыска** — короткий
**кыскача** — вкратце
**кыстыбый** — кыстыбый
**кычыткан** — крапива
**кышын** — зимой
**кыяр** — огурец

# Л

**лалә** — тюльпан
**ләкин** — но, однако

# М

**маҗара** — приключение
**май** — масло
**мактый** — хвалит
**маңгай** — лоб
**матур** — красивый
**мәгълүмат** — информация
**мәгънә** — смысл
**мәдәният** — культура
**мәк** — мак
**мәкаль** — пословица
**мәктәп** — школа
**мәсәл** — басня
**мәсьәлә** — задача
**мәтрүшкә** — душица
**мәче** — кошка
**мәчет** — мечеть
**менә** — вот
**менә** — поднимается
**мендәр** — подушка
**мескен** — несчастный
**ми** — мозг
**миләш** — рябина
**милли** — национальный
**мин** — я
**минеке** — мой
**минем** — мой, у меня
**миңа** — мне
**мисал** — пример
**мич** — печь
**могҗиза** — чудо
**монда** — здесь
**мөмкин** — можно
**мөстәкыйль** — самостоятельный
**муен** — шея

# Н

**намус** — совесть
**нарат** — сосна
**начар** — плохой
**нәкъ** — точь-в-точь, именно
**нәрсә** — что
**нәүрүз** — навруз (новый год по восточному календарю)
**нәфис** — изящный
**нәшрият** — издательство
**нур** — луч

# О

**озак** — долго
**озат** — проводи
**озын** — длинный
**озын колаклы** — длинноухий
**олы** — большой; старший
**он** — мука
**онытырга** — забывать
**орлык** — семя
**оста** — мастер, умелец; искусный; умело
**оч I** — лети
**оч II** — макушка, остриё
**очлый** — точит
**очрашу** — встреча
**очсыз I** — тупой; исписанный (о карандаше)
**очсыз II** — дешёвый
**оя** — гнездо
**оялырга** — стесняться
**оят** — стыд

# Ө

**өз** — рви
**өзәргә** — рвать
**өзгәлән** — разрывайся
**өзек** — отрывок
**өтер** — запятая
**өчпочмак** — треугольник

# П

**пәрәмәч** — перемяч
**пәрдә** — занавес
**песи** — кошка
**песнәк** — синица
**пешер** — вари, свари, пеки
**пеште** — сварилось
**пилмән** — пельмени
**почмак** — угол
**поши** — лось
**пөхтә** — опрятный
**пычак** — нож
**пычрак** — грязно; грязный

# Р

**рәсем** — рисунок
**рәсем ясый** — рисует
**рәссам** — художник
**рәхәт** — приятно, хорошо
**рәхим ит(егез)** — добро пожаловать
**риза** — согласен, согласна
**ризык** — пища
**рөхсәт** — разрешение
**рөхсәт ит(егез)** — разреши(те)

# С

**сабын** — мыло
**сабыр** — терпеливо; терпеливый
**савыт** — посуда
**саен** — каждый
**саескан** — сорока
**саз** — болото
**сай** — мелко; мелкий
**сайларга** — выбирать
**сак** — осторожный
**сакла** — береги
**салават күпере** — радуга
**салам** — солома
**салкын** — холодно
**самавыр** — самовар
**санамыш** — считалка
**саран** — скупой
**сары** — жёлтый
**сатучы** — продавец
**сау бул(ыгыз)** — до свидания
**саулык** — здоровье
**саф** — чистый; свежий
**сәбәп** — причина

**сәгать** — часы
**сәлам** — привет
**сәламәт** — здоровый
**сәләт** — способность
**сәнгать** — искусство
**сәнгатьле** — художественный
**сәхнә** — сцена
**сәяхәт** — путешествие
**себерә** — подметает
**себерке** — метла, веник
**сезнеке** — ваше
**сезнеңчә** — по-вашему
**сеңлем** — моя сестрёнка
**сер** — секрет
**сибә** — поливает
**сиз** — чувствуй
**сизә** — чувствует
**сикер** — прыгай
**сикерү** — прыжок
**синеке** — твой
**соклану** — восхищение
**соң** — поздно, поздний; после того
**соңга кала** — опаздывает
**соңгы** — последний
**сорарга** — спрашивать
**сорау** — вопрос
**соры** — серый
**сөекле** — любимый
**сөенә** — радуется
**сөенеч** — радость
**сөйлә** — расскажи
**сөйләм** — речь
**сөйләш** — разговаривай, поговори
**сөртергә** — вытирать
**сөт** — молоко
**сөю** — любить; любовь
**сөяк** — кость
**сөяргә I** — любить
**сөяргә II** — прислонить, приставить
**су** — вода
**суалчан** — червь
**сугыш** — война
**сугышу** — драка, бой
**сузарга** — тянуть
**сузык** — гласный
**сукыр** — слепой
**сул** — левый
**сулга** — налево, влево
**сулдан** — слева
**сулыш** — дыхание
**сурәт** — изображение
**сүз** — слово
**сүзлек** — словарь
**сүнгән** — потухший
**сүтәргә** — разбирать; размотать

# Т

**таба** — по направлению к ...
**табан** — ступня
**табарга** — находить
**табиб** — врач
**табигать** — природа
**табигать белеме** — природоведение
**табын** — накрытый стол
**табыш** — находка
**табышмак** — загадка
**тавык** — курица
**тавыш** — голос
**тагы, тагын** — опять, ещё
**таза** — здоровый
**тамак** — горло
**тамаша** — зрелище
**тамчы** — капля
**тамыр** — корень
**тантана** — торжество
**танылган** — известный
**таныш** — знакомый
**тапкыр I** — находчивый
**тапкыр II** — раз

**тапкырларга** — множить, умножить
**тапкырлау** — умножение
**тапты** — нашёл
**тапшыру** — передача
**тар** — узкий
**тарих** — история
**тартма** — коробка
**тартык** — согласный
**тартырга** — тянуть
**татлы** — сладкий
**тату** — дружно
**таш** — камень
**таяк** — палка
**тәмле** — вкусно; вкусный
**тәнәфес** — перерыв, перемена
**тәрәзә** — окно
**тәрбияле** — воспитанный
**теге** — тот
**тегендә** — там
**тегермән** — мельница
**тез** — колено
**тел** — язык
**телдән** — устно
**тели** — хочет
**теш** — зуб
**тизәйткеч** — скороговорка
**тиздән** — скоро
**тик** — однако
**токмач** — лапша
**токым** — порода
**тор** — встань
**тот** — держи
**төлке** — лиса
**төн** — ночь
**төнлә** — ночью
**төрле** — различный
**төс** — цвет
**төсле** — цветной
**төчкерә** — чихает
**төшә** — опускается
**туган** — родственник
**тугры** — преданный, верный
**тузан** — пыль
**тукта** — стой
**тукталыш** — остановка
**туры** — прямой; прямо
**турыга** — прямо
**турында** — о, об
**түбәндә** — внизу
**түгәрәк** — круглый
**түләгез** — платите
**түрдән уз** — проходи
**түшәм** — потолок
**тыныч** — тихий; тихо
**тыңла** — слушай
**тырыш** — старательный

# У

**уен** — игра
**уз** — проходи
**узган** — прошлый
**уң** — правый
**уңга** — направо
**уңган** — деловой; умелый
**уңдырышлы** — плодородный
**уңыш** — урожай
**урнаш** — устройся, устраивайся
**урнашкан** — находится
**урта** — середина
**уртак** — общий, совместный
**урындык** — стул
**урын-җир** — постель
**усал** — злой
**ут** — огонь
**уч** — ладонь
**уян** — проснись
**уят** — разбуди

# Ү

**үз** — свой
**үзара** — между собой

**үзгәртергә** — менять
**үзе** — сам, сама, само
**үзеңеке** — свой
**үлән** — трава
**үпкә I** — лёгкие
**үпкә II** — обида
**үс** — расти
**үстер** — выращивай
**үт** — проходи
**үткен** — острый, остроумный

# Ф

**файда** — польза
**файдалы** — полезно; полезный
**фасыл** — время года
**фән** — наука
**фил** — слон

# Х

**хайван** — животное
**хак** — цена
**халык** — народ
**хат** — письмо
**хата** — ошибка
**хатын** — жена
**хатын-кыз** — женщина
**хәерле көн** — добрый день
**хәерле юл** — доброго пути
**хәзер** — сейчас
**хәреф** — буква
**хәтер** — память
**хезмәт** — труд
**хөрмәтле** — уважаемый
**хуҗа** — хозяин
**хуш исле** — душистый
**хуш(ыгыз)** — прощай(те)
**хуш киләсез** — добро пожаловать

# Һ

**һаман** — всё ещё
**һәйкәл** — памятник
**һәлак булды** — погиб
**һәрбер** — каждый
**һәрвакыт** — всегда
**һәркем** — каждый
**һәркөн** — каждый день
**һәртөрле** — всякий
**һичкем** — никто
**һөнәр** — ремесло

# Ч

**чакыра** — зовёт
**чакыру** — приглашение
**чалбар** — брюки
**чана** — сани
**чаңгы** — лыжи
**чәч** — волосы
**чебен** — муха
**чеби** — цыплёнок
**чир** — болезнь
**чирәм** — трава
**чирек** — четверть
**чишмә** — родник
**чөгендер** — свёкла
**чөнки** — потому что
**Чулман** — Кама
**чүлмәк** — горшок
**чүп** — мусор
**чүпрәк** — тряпка
**чыдарга** — терпеть
**чык I** — выходи
**чык II** — роса
**чыршы** — ель

# Ш

**шагыйрь** — поэт
**шакмаклы** — в клетку
**шалтырат** — позвони
**шат** — радостный
**шатланды** — обрадовался
**шәфкатьле** — милосердный
**шуам** — катаюсь
**шул** — тот
**шулпа** — бульон
**шунда** — там
**шуңа** — поэтому, потому
**шушы** — этот

# Ы

**ылыс** — хвоя
**ыңгырашу** — стон
**ыргыт** — бросай
**ышан** — верь
**ышанмау** — недоверие
**ышанмыйча** — не доверяя
**ышанычлы** — надёжный

# Э

**эз** — след
**эзлә** — ищи
**эзләргә** — искать
**эзсез** — бесследно
**эл** — вешай
**элгеч** — вешалка
**энә, инә** — иголка
**эндәш** — откликнись, отзовись
**эре** — крупный
**эремчек** — творог
**эри** — тает
**эскәтер** — скатерть
**эссе** — горячий, жаркий
**эч** — пей
**эчендә** — внутри
**эчке** — внутренний
**эшләпә** — шляпа
**эшчән** — трудолюбивый

# Ю

**ю** — мой
**юа** — моет
**юан** — толстый
**юаш** — смирный, тихий, робкий
**югалту** — потеря
**югары** — высоко; высокий
**юеш** — мокрый
**юка** — тонкий
**юкә** — липа
**юкка** — напрасно
**юклык** — отсутствие
**юл** — дорога
**юләр** — дурак, глупый
**юлдаш** — спутник
**юлчы** — путник
**юмарт** — щедрый
**юньле** — порядочный, толковый
**юньсез** — бестолковый
**юрган** — одеяло
**юри** — нарочно
**ютәл** — кашель
**юын** — умывайся

# Я

**ябарга** — закрывать
**ябу** — закрытие
**ябык** — закрыто; закрытый
**ябыштырырга** — клеить, приклеивать
**ябышырга** — липнуть; цепляться; держаться
**ява** — идёт (снег, дождь)
**ягымлы** — ласковый

**язма** — письменно; письменный
**як** — сторона, край
**яка** — ворот, воротник
**яки** — либо
**якларга** — защищать
**якын** — близко
**як-якка** — по сторонам
**ял** — отдых
**ялангач** — голый
**ялган** — ложь; ложный
**ялганчы** — лгун
**ялгыз** — одинокий
**ялгыш** — ошибка; ошибочно; ошибочный
**ялкау** — ленивый
**ямь** — прелесть, красота
**ямьле** — прелестный, красивый
**ямьсез** — некрасивый
**яна** — горит
**янәшә** — рядом
**янына** — к (дому, школе)
**яңак** — щека
**яңгыр** — дождь
**яңгырый** — звучит
**яра** — рана
**яраткан** — любимый
**ярату** — любовь
**яратырга** — любить
**ярдәм** — помощь
**ярма** — крупа
**ярты** — половина
**ярыш** — соревнование
**яса** — делай
**ясарга** — делать
**ят I** — чужой, посторонний
**ят II** — ложись
**ятарга** — ложиться
**ятла** — выучи
**ятларга** — выучить
**яттан** — наизусть
**яулык** — платок
**яшен** — молния
**яшерен** — тайно
**яшерергә** — прятать
**яшь I** — молодой
**яшь II** — годы, лета
**яшь III** — слеза
**яшьләр** — молодёжь
**яшьлек** — молодость

Татарча-русча сүзлек

# Эчтәлек

**Без мәктәптә**

1–22 нче дәресләр ........................................................ 3

**Мин — өйдә булышчы**

23–41 нче дәресләр......................................................34

**Дуслар белән күңелле**

42–48 нче дәресләр......................................................60

**Безнең бәйрәмнәр**

49–66 нчы дәресләр ....................................................70

**Татарстан — туган җирем**

67–71 нче дәресләр......................................................93

**Туган як табигате**

72–85 нче дәресләр......................................................99

**Без спорт яратабыз**

86–92 нче дәресләр.................................................... 113

**Без юлда**

93–102 нче дәресләр .................................................. 119

**Сүзлек** ............................................................................128

Учебное издание

**Хайдарова** Роза Закиевна
**Ахметзянова** Гульназ Магсумзяновна

# ТАТАР ТЕЛЕ

**5 класс**

Учебник для образовательных организаций
основного общего образования

**Группа разработчиков учебно-методического комплекта**
Авторы *Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова*
Руководитель проекта *А.Т. Низамеева*
Художественный редактор *С.В. Киатров*
Руководитель группы художников и верстальщиков *Д.И. Бариев*
Вёрстка *Е.Б. Шараповой*
Координатор проекта *А.М. Ганиев*
Технический руководитель *И.М. Низаметдинов*
Редакторы *Ф.Ш. Ахметзянова, Г.М. Ахметзянова, И.А. Закиев*
Художники *А.Е. Гаранина, П.К. Михайлова, А.Я. Смольская,*
*Н.К. Авдеева, Г.И. Гилазетдинова, А.А. Бронникова, Ж.А. Буланкова*

Соответствует требованиям СанПиН 2.4.7.1166-02 «Гигиенические требования к изданиям учебников для общего и начального профессионального образования».

Подписано в печать 10.08.2025. Формат 84×108 1/16 . Бумага офсетная. Гарнитура «Школьная».
Печать офсетная. Уч.-изд. л. 8. Тираж экз. Заказ

Издательство «Татармультфильм».
420066, г. Казань, пер. Односторонки Гривки, д. 32, помещ. 2.
**www.tatarmultfilm.ru**

Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленных издательством «Татармультфильм» материалов в типографии

**Издательство «Татармультфильм»**
разрабатывает и выпускает:

— учебники,
— электронные учебники,
— мультимедийные пособия,
— методические пособия,
— рабочие тетради,
— художественно-анимационные издания,
— интерактивные приложения.

**www.tatarmultfilm.ru**

Дополнительные материалы по изучению татарского языка и литературы для классных и внеурочных занятий на сайте **www.balarf.ru (www.бала.рф).**

# Исемнәрнең килешләр
# Склонение имён

| Падежи | Вопросы |
|---|---|
| **Баш килеш**<br>(Именительный падеж) | Кем? — Кто?<br>Нәрсә? — Что? |
| **Иялек килеше**<br>(Притяжательный падеж) | Кемнең? — Кого?<br>Нәрсәнең? — Чего? |
| **Юнәлеш килеше**<br>(Направительный падеж) | Кемгә? — Кому?<br>Нәрсәгә? — Чему?<br>Кая? — Куда? |
| **Төшем килеше**<br>(Винительный падеж) | Кемне? — Кого?<br>Нәрсәне? — Что? |
| **Чыгыш килеше**<br>(Исходный падеж) | Кемнән? — От кого?<br>Нәрсәдән? — От чего?<br>Кайдан? — Откуда? |
| **Урын-вакыт килеше**<br>(Местно-временной падеж) | Кемдә? — У кого?<br>Нәрсәдә? — У чего?<br>Кайда? — Где? |

## белән төрләнеше существительных

| Аффиксы | Единственное число |
|---|---|
| — | **бакча** — огород<br>**шәһәр** — город |
| **-ның/-нең** | **бакчаның** — огорода<br>**шәһәрнең** — города |
| **-га/-гә**<br>**-ка/-кә** | **бакчага** — в огород<br>**шәһәргә** — в город<br>**паркка** — в парк<br>**кибеткә** — в магазин<br>**урамга** — на улицу |
| **-ны/-не** | **бакчаны** — огород<br>**шәһәрне** — город |
| **-нан/-нән**<br>**-дан/-дән**<br>**-тан/-тән** | **урамнан** — с улицы<br>**киемнән** — с одежды<br>**бакчадан** — с огорода<br>**шәһәрдән** — из города<br>**парктан** — из парка<br>**кибеттән** — из магазина |
| **-да/-дә**<br>**-та/-тә** | **урамда** — на улице<br>**шәһәрдә** — в городе<br>**паркта** — в парке<br>**кибеттә** — в магазине |

ФГОС



ISBN 978-5-906508-55-3

Татармультфильм

издательство
«Татармультфильм»